РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2021 елның 29 октябре Кукмара ш. № 83

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмә хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәне әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Кукмара муниципаль районындагы бюджет процессы турындагы Нигезләмә әлеге карар редакциясендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә, 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджеттан башлап барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.
3. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында бюджет процессы турында» Кукмара муниципаль районы Советының 2019 елның 25 октябрендәге 249 номерлы, «Кукмара муниципаль районы Советының 2019 елның 25 октябрендәге 249 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев

Кукмара муниципаль район Советының 2021 елның 29 октябрендәге 83 номерлы карарына кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА БЮДЖЕТ ПРОЦЕССЫ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

## 1 Бүлек ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 Статья Әлеге Нигезләмә белән җайга салына торган хокукый мөнәсәбәтләр һәм аларның хокукый нигезе

Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Салым кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы (алга таба – Район Уставы) нигезендә эшләнде һәм Кукмара муниципаль районы (Алга таба – Район) бюджетын төзү, карау, раслау, үтәү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту барышында, шулай ук муниципаль бурыч алулар һәм Районның муниципаль бурычы белән идарә итү барышында бюджет хокук мөнәсәбәтләре субъектлары арасында барлыкка килә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала.

Районның бюджет хокук мөнәсәбәтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Район Уставы, әлеге Нигезләмә, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы бюджет законнарының башка актлары һәм Районның җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 2 статья. Төшенчәләр һәм терминнар

Әлеге Нигезләмәдә кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе Бюджет кодексы билгеләгән мәгънәләрендә кулланыла.

### 3 статья. Район бюджетының хокукый формасы

Район бюджетын формалаштыру, раслау, үтәү һәм аның үтәлешен контрольдә тоту Районның җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль гамәлгә ашырыла. Район бюджеты Район Советының муниципаль хокукый акты формасында эшләнә һәм раслана.

Район бюджеты Район Советының муниципаль хокукый акты нигезендә бер елга (чираттагы финанс елына) яки өч елга (чираттагы финанс елына һәм план чорына) төзелә һәм раслана.

### 4 статья. Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану

Район бюджеты күрсәткечләренең Россия Федерациясе бюджет системасының башка дәрәҗәдәге бюджетлары белән чагыштырмасын тәэмин итү максатларында, Район бюджетын төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә, аның

үтәлеше турында хисап формалаштырганда, Россия Федерациясенең Федераль закон белән расланган бюджет классификациясе кулланыла.

### 5 статья. Бюджет процессы принциплары

Районда бюджет процессы Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнгән Россия Федерациясе бюджет системасы принципларына нигезләнә:

- Россия Федерациясе бюджет системасының бердәмлеге;
- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында керемннәр һәм чыгымнар, бюджет кытлыкларын финанслау чыганакларын бүлү
- бюджетларның мөстәкыйльлеге;
- Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең бюджет хокукларының тигезлеге;
- керемнәр, чыгымнар һәм бюджет кытлыкларын финанслау чыганаклары чагылышының тулылыгы;
- Район бюджетының баланслылыгы;
- бюджет акчаларын куллануның нәтиҗәлелеге;
- бюджет чыгымнарын гомуми (җыелма) каплау;
- үтә күренмәлелек ( ачыклык);
- Район бюджетының дөреслеге;
- бюджет акчаларының адреслылыгы һәм максатчан характерлылыгы;
- Район бюджеты чыгымнарының ведомство буйсынуында булуы;
- кассаның бердәмлеге.

### 6 статья. Бюджет процессы этаплары

Районда бюджет процессы түбәндәге этапларны үз эченә ала:

- Районның һәм аның икътисады тармакларының социаль-икътисади үсеше фаразларын эшләү;
- Район бюджеты проектын төзү;
- Район бюджеты проекты һәм Район бюджеты үтәлеше турында хисап буенча гавами тыңлаулар үткәрү;
- Район бюджетын карау һәм раслау;
- Район бюджеты үтәү;
- тиешле елга Район бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү;
- Район бюджеты үтәлеше турында хисапны раслау;

Бюджет процессының барлык этапларында муниципаль финанс контроле гамәлгә ашырыла.

### 7 статья. Бюджет процессында катнашучылар

Районда бюджет процессында катнашучылар булып торалар:

- Район Советы;
- Район Башлыгы;
- Район Башкарма комитеты (алга таба –Район Башкарма комитеты);
- Район Финанс-бюджет палатасы;
- Район Контроль-хисап палатасы;

- бюджет акчаларын баш бүлүче (алга таба – ГРБС), бюджет акчаларын бүлүчеләр (алга таба – РБС);

- бюджет керемнәренең баш администраторлары;

- бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары;

- бюджет акчаларын алучылар (алга таба – ПБС);

- Россия Федерациясе Бюджет законнары белән бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салу, Районда бюджет процессын оештыру һәм гамәлгә ашыру буенча бюджет вәкаләтләре йөкләнгән башка органнар.

**8 статья. Бюджет процессында катнашучыларның бюджет вәкаләтләре**

1. Район Советы:

- чираттагы финанс елы башына Район бюджетын карый һәм раслый;

- Район бюджеты үтәлеше турында хисапны раслый;

- Район Советының агымдагы елга Район бюджеты турындагы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертә;

- үз утырышларында, комитетлар, комиссияләр, Район Советының эшче төркемнәре утырышларында, Район Советы үткәргән тыңлаулар барышында һәм депутат запрослары белән бәйле рәвештә, Район бюджеты үтәлешенең аерым мәсьәләләрен карау барышында контрольне гамәлгә ашыра;

- җирле салымнар һәм җыемнар кертә, алар буенча ставкалар күләмен билгели һәм аларны түләү буенча Россия Федерациясе салым законнары тарафыннан бирелгән хокуклар кысаларында ташламалар бирә;

- Район бюджетын раслаганчы, үз компетенциясе кысаларында Чираттагы финанс елы башыннан үз көченә керә торган салымнар һәм җыемнар турында норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында хокукый актлар кабул итә;

- муниципаль милектә булган мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибен, мөлкәттән файдаланудан кергән табышларны Район бюджетына җибәрү тәртибен билгели;

- максатчан бюджет фондлары акчаларын тоту тәртибен билгели;

- бюджет законнары һәм Район Уставы нигезендә башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

2. Район Башлыгы:

- Район исеменнән дәүләт хакимияте органнары, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары белән икътисадый һәм социаль-мәдәни өлкәләрдә хезмәттәшлек итү турында шартнамәләр һәм килешүләр, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлек итү һәм гамәлләрне координацияләү турында шартнамәләр һәм килешүләр төзи;

- гамәлдәге законнар нигезендә башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

3. Район Башкарма Комитеты:

- Район бюджет проектын төзү тәртибен һәм срокларын билгели;

- Район бюджет проектын төзүне тәэмин итә;

- Районның социаль-икътисади үсеше фаразын, Район бюджетының керем фаразын эшләүне тәэмин итә;

чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен билгели;

- әлеге Нигезләмәнең 29 пунктында күрсәтелгән исемлек нигезендә кирәкле документлар һәм материаллар белән район Советы каравына Район бюджеты проектын кертә;

- Район бюджетының үтәлешен һәм бюджет хисаплылыгын төзүне тәэмин итә;

- Район бюджеты үтәлеше турындагы хисап проектын Район Советы каравына кертә;

- Район бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карар проектларын Район Советы каравына кертә;

- муниципаль программаларны раслый һәм аларны гамәлгә ашыру срокларын раслый;

- Районның чыгым йөкләмәләрен билгели һәм башкара;

- җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү, юкка чыгару, Район бюджеты акчаларыннан чыгымнарны гамәлгә ашыру буенча хокукый актлар проектларына (Район Башкарма комитеты җитәкчесе йөзендә) нәтиҗәләр әзерләүне, җирле салымнар буенча салым ташламаларын кертү һәм гамәлдән чыгару буенча тәкъдимнәр әзерләүне, Район бюджетын формалаштыруга кагылышлы норматив хокукый актлар проектларына бәяләмәләр әзерләүне оештыра;

- Район Уставы нигезендә муниципаль бурыч белән идарә итүне тәэмин итә;

- муниципаль бурыч кенәгәсенә кертелә торган, бюджет законнары белән билгеләнмәгән мәгълүмат составын билгели;

- бюджетара трансфертларны бюджетара трансфертларны бүлү методикасын һәм бирү тәртибен эшләүне тәэмин итә һәм раслый;

- муниципаль эчке бурыч алуларны гамәлгә ашыра, кредитлар җәлеп итү өчен кредит килешүләре һәм шартнамәләр төзи, тиешле елга Район бюджеты турында карарда билгеләнгән күләмнәр чикләрендә Район исеменнән муниципаль гарантияләр бирә;

- муниципаль милектәге капиталь төзелеш объектларына бюджет инвестицияләрен әзерләүне тәэмин итә һәм гамәлгә ашыра;

- Район икътисады һәм социаль өлкәсе торышын характерлый торган статистик күрсәткечләр җыюны һәм күрсәтелгән мәгълүматларны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тапшыруны оештыра;

- расланган бюджет нигезендә үз вәкаләтләре чикләрендә Район акчалары белән эш итә;

- бюджет законнары һәм Район Уставы нигезендә башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

- Район Финанс-бюджет палатасы:

- Район бюджеты проектын төзү һәм бюджет үтәлеше өлешендә методологик җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

- Район бюджеты проектын турыдан-туры төзи һәм, әлеге Нигезләмәнең 35 пунктында күрсәтелгән исемлек нигезендә кирәкле документлар һәм материаллар белән, Район Советына кертү өчен, Район Башкарма комитетына тапшыра;

- җыелма бюджет язмасы һәм Районның касса планы нигезендә Район бюджетының үтәлешен оештыра;

- бюджет язмасын төзи, алып бара;

- бюджет хисабы төзү тәртибен билгели;

- Район бюджеты үтәлеше турында хисап төзи, агымдагы елга Район бюджетының көтелгән үтәлешен бәяли һәм Башкарма комитетка тапшыра;

- муниципаль бурыч кенәгәсен алып бара, шул исәптән муниципаль гарантияләрне бирү, муниципаль гарантия алучыларның муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән төп йөкләмә буенча бурычларын үтәүләрен, бирелгән муниципаль гарантияләр буенча Район бюджеты акчалары исәбеннән түләүләрне гамәлгә ашыру исәбен алып бара;

- ведомство буйсынуындагы бюджет учреждениеләренең бюджет сметаларын раслау тәртибе буенча тәкъдимнәр әзерли;

- Башкарма комитет йөкләмәсе буенча кире кайтару нигезендә Район бюджеты акчалары, бюджет инвестицияләре бирү турында шартнамәләр төзи;

- кире кайтару нигезендә аларны алучылар киселешендә бюджет акчаларын бирү реестрын алып бара;

- кире кайтару нигезендә бюджет акчаларын алучыларның, муниципаль гарантия алучыларның, бюджет инвестицияләре алучыларның финанс хәлен тикшерә;

- кире кайтару нигезендә бирелгән бюджет акчалары буенча кичектерелгән бурыч суммаларын, бюджет акчаларыннан файдаланган өчен вакытында түләнмәгән процентлар, шулай ук бюджет акчаларын үз вакытында кайтармаган өчен пеняларны бәхәссез тәртиптә түләттерә;

- максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган бюджет акчаларын түләттерә;

- кичектерелгән һәр көн өчен Россия Банкы рефинанслау ставкасының өч йөздән бер өлеше күләмендә бюджет акчаларын кертүгә (зачисление) яки күчерүгә (перечисление) түләү документларын вакытында үтәмәгән өчен кредит оешмаларыннан пеняны бәхәссез тәртиптә түләттерә;

- бюджет законнары белән билгеләнгән субвенцияләр, бюджетара субсидияләр һәм башка субсидияләр алучылар тарафыннан аларны биргәндә билгеләнгән шартларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

- җирле салымнарны, җыемнарны билгеләү, үзгәртү, юкка чыгару, Район бюджеты акчаларыннан чыгымнарны гамәлгә ашыру, җирле салымнар буенча салым ташламаларын кертү яки юкка чыгару буенча хокукый актлар проектларына бәяләмә бирә;

- Район бюджетын формалаштыруга кагылышлы норматив хокукый актлар проектларына бәяләмә бирә;

- Районның социаль-икътисади үсеше фаразын эшләүдә, чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет һәм салым сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен билгеләүдә катнаша;

- бюджет законнары нигезендә башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

5. Район Контроль-хисап палатасы:

- Район бюджеты үтәлешен, Район бюджеты проектын, аның үтәлеше буенча хисап әзерләү һәм карау буенча билгеләнгән тәртипне үтәүгә алдан һәм алга таба тышкы контроль оештыра һәм үткәрә;

- бюджет акчаларын куллануның экономиялелеген һәм нәтиҗәлелеген билгеләүгә юнәлдерелгән эффектлылык аудиты үткәрә;

- бюджет турындагы карарлар проектларына, аңа үзгәрешләр кертү турында норматив хокукый актларга, шул исәптән бюджет күрсәткечләренең (параметрларының һәм характеристикаларының) нигезлелегенә экспертиза ясый;

- җирле үзидарә органнары тарафыннан төзелә торган муниципаль программаларга, шартнамәләргә һәм Район бюджеты мәсьәләләренә кагылышлы башка кирәкле документларга экспертиза үткәрә;

- бюджет процессына анализ һәм мониторинг үткәрә, шул исәптән бюджет процессында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча тәкъдимнәр әзерли;

- Район бюджетының аерым бүлекләре һәм статьялары буенча комплекслы ревизияләр, тематик тикшерүләр һәм тикшереп чыгулар (обследования) үткәрә;

- заказчы, вәкаләтле орган яки махсуслаштырылган оешма яисә конкурс, аукцион яки котировка комиссиясе тарафыннан муниципаль заказларны урнаштыру турында Россия Федерациясе законнарын һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларын үтәүне планлы һәм планнан тыш тикшерүләр оештыра һәм үткәрә;

- Район Советы, Район Башлыгы карарлары, Район Советы депутатлары запрослары буенча бәяләмә һәм җаваплар әзерли, тәкъдим итә;

- муниципаль милектә булган мөлкәт белән идарә итү һәм аның белән эш итүнең билгеләнгән тәртибен үтәүне контрольдә тота;

- Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмәләр әзерли;

- эчке финанс контроле һәм эчке финанс аудитының бюджет акчаларын баш администраторлар тарафыннан гамәлгә ашыруны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләүне гамәлгә ашыра;

- бюджет законнары һәм Район Советының норматив хокукый актлары нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

6. Бюджет акчаларын баш бүлүче (бүлүче).

Район бюджетының бюджет акчаларын баш бүлүчесе (ГРБС) – Район Башкарма комитеты.

ГРБС түбәндәге бюджет вәкаләтләренә ия:

- аңа расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә бюджет акчаларын файдалануның нәтиҗәлелеген, адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә;

- үз карамагындагы бюджет акчаларын бүлүчеләрнең һәм алучыларның исемлеген төзи;

- аңа расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә үтәлергә тиешле чыгым йөкләмәләре реестрын алып баруны тәэмин итә;

- бюджетның тиешле чыгымнарын планлаштырны гамәлгә ашыра, бюджет ассигнованиеләрен нигезләүне төзи;

- бюджет язмасын төзүне, алып баруны тәэмин итә, бюджет язмасын раслый, бюджет ассигнованиеләрен, бюджет йөкләмәләре лимитларын ведомство буйсынуындагы бюджет акчаларын бүлүчеләр һәм бюджет акчаларын алучылар буенча бүлә;

- бюджет йөкләмәләре лимитларын формалаштыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

- җыелма бюджет язмасын формалаштыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

- казна учреждениеләре булып торучы ведомство буйсынуындагы бюджет акчаларын алучыларның бюджет сметаларын раслау тәртибен билгели;

- муниципаль биремнәр формалаштыра һәм раслый;

- бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертларны, шулай ук бюджет законнарында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләрен алучылар тарафыннан аларны биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртипне үтәүне тәэмин итә;

- ГРБСның бюджет хисабын формалаштыра;

- муниципаль берәмлек исеменнән үз карамагындагы бюджет акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләре буенча җавап бирә;

бюджет законнарында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

Район бюджеты ГРБСы судта муниципаль берәмлек исеменнән түбәндәге дәгъвалар буенча җавап бирүче вәкиле буларак чыгыш ясый:

1) Район Башкарма комитеты органнарының яки әлеге органнарның вазыйфаи затларының ведомствога караган законсыз гамәлләре нәтиҗәсендә, шул исәптән, Район башкарма комитеты тарафыннан законга яисә башка хокукый актка туры килми торган актлар чыгару нәтиҗәсендәфизик затка яки юридик затка китерелгән зыянны каплау турында;

2) ведомство буйсынуындагы бюджет учреждениеләренең акчалата йөкләмәләре буенча субсидиар җаваплылык тәртибендә бирелә торган;

Район бюджетының бюджет акчаларын бүлүче (РБС) – Район Башкарма комитеты органы, бюджет ассигнованиеләрен һәм бюджет йөкләмәләре лимитларын ведомство буйсынуындагы бюджет акчаларын бүлүчеләр һәм (яисә) бюджет акчаларын алучылар арасында бүләргә хокуклы казна учреждениеләре.

РБС түбәндәге бюджет вәкаләтләренә ия:

- бюджетның тиешле чыгымнарын планлаштыруны гамәлгә ашыра;

- бюджет ассигнованиеләрен, бюджет йөкләмәләре лимитларын ведомство буйсынуындагы бюджет акчаларын бүлүчеләргә һәм (яки) алучыларга бүлә һәм бюджетның тиешле өлешен үти;

- үзе аның карамагында булган бюджет акчаларын баш бүлүчегә бюджет язмасын формалаштыру һәм үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

- бюджетара субсидияләрне, субвенцияләрне һәм максатчан билгеләнештәге башка бюджетара трансфертларны, шулай ук бюджет законнарында билгеләнгән башка субсидияләр һәм бюджет инвестицияләрен алучылар тарафыннан аларны биргәндә билгеләнгән шартларны, максатларны һәм тәртипне үтәүне тәэмин итә;

- ГРБС билгеләгән очракта һәм тәртиптә ГРБСның аерым бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

7. Район бюджеты керемнәренең баш администраторлары түбәндәге бюджет вәкаләтләренә ия:

Район бюджеты керемнәренең ведомство буйсынуындагы администраторлары исемлеген формалаштыралар;

урта сроклы (среднесрочный) финанс планын һәм (яки) Район бюджеты проектын төзү өчен кирәкле белешмәләр тапшыралар;

касса планын төзү һәм алып бару өчен белешмәләр тапшыралар;

Район бюджет керемнәре баш администраторының бюджет хисабын формалаштыралар һәм тапшыралар;

бюджет законнарында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар.

Район бюджеты керемнәре администраторлары түбәндәге бюджет вәкаләтләренә ия:

бюджетка түләүләрнең, аның буенча пенялар һәм штрафлар түләүнең дөреслеген, тулылыгын һәм үз вакытында башкарылуын исәпләү, исәпкә алу һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыра;

бюджетка түләүләр, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүне гамәлгә ашыра;

Район бюджетына артык түләнгән (түләттерелгән) түләүләрне, пенялар, штрафларны шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган өчен процентларны һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентларны кире кайтару турында карар кабул итә, һәм ул Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә кире кайтаруны гамәлгә ашыру өчен Федераль казначылык органына йөкләмә бирә;

Район бюджетына түләүләргә зачет (төгәлләштерү) турында карар кабул итә һәм Федераль казначылык органына хәбәрнамә бирә;

Район бюджеты керемнәренең баш администраторы билгеләгән очракта һәм тәртиптә бюджет керемнәренең баш администраторына тиешле баш администратор вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле белешмәләр һәм бюджет хисабын формалаштыралар һәм тапшыралар;

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртип нигезендә дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында Дәүләт мәгълүмат системасына физик һәм юридик затлар тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләргә акча түләү өчен, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы

бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган бүтән түләүләрне түләү өчен кирәкле мәгълүмат бирә, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

бюджет законнарында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар.

8. Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары түбәндәге бюджет вәкаләтләренә ия:

Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының үзенә буйсынучы администраторлары исемлекләрен формалаштыралар;

Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне, Район бюджетының бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш, планлаштыруны (фаразлауны) гамәлгә ашыра;

Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын түләү өчен аның карамагына бүлеп бирелгән ассигнованиеләрне куллануның адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итәләр;

бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының ведомство буйсынуындагы администраторлары буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлә һәм бюджетның тиешле өлешен үтиләр;

бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторының бюджет хисабын формалаштыралар.

Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының администраторлары түбәндәге бюджет вәкаләтләренә ия:

- Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча керемнәрне һәм түләүләрне, Район бюджетының бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш, планлаштыруны (фаразлауны) гамәлгә ашыра;

бюджет дефицитын финанслау чыганакларының бюджетка керүенең тулылыгын һәм үз вакытында булуын контрольдә тота;

Район бюджетына керүне һәм Район бюджетыннан Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча түләүләрне тәэмин итәләр;

бюджет хисабын формалаштыралар һәм тапшыралар;

Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының тиешле баш администраторы тарафыннан билгеләнгән очракта һәм тәртиптә үзе аның карамагында булган Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары баш администраторының аерым бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар;

бюджет законнарында һәм аның нигезендә кабул ителә торган бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган муниципаль хокукый актларда билгеләнгән башка бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыралар.

9. Бюджет акчаларын алучы.

Район бюджеты ПБСы (бюджет акчаларын алучылары) – ГРБС, РБС карамагындагы Район Башкарма комитеты органы, тиешле бюджет акчалары исәбеннән бюджет йөкләмәләрен кабул итү һәм (яисә) үтәү хокукына ия казна учреждениесе.

ПБС түбәндәге бюджет вәкаләтләренә ия:

бюджет сметасын төзи һәм башкара;

- җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бюджет йөкләмәләрен кабул итә һәм (яисә) башкара:

- үзенә каралган бюджет ассигнованиеләрен куллануның нәтиҗәлелеген, максатчан характерын тәэмин итә;

- бюджет акчаларын тиешле бүлүчегә бюджет язмасын үзгәртү буенча тәкъдимнәр кертә;

- бюджет исәбен алып бара (бюджет исәбен алып баруны тәэмин итә);

- бюджет хисаплылыгын формалаштыра (бюджет хисаплылыгын формалаштыруны тәэмин итә) һәм бюджет акчаларын алучының бюджет хисабын тиешле бюджет акчаларын баш бүлүчегә (бүлүчегә) тапшыра;

бюджет законнарында һәм аның нигезендә кабул ителгән бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган норматив хокукый актларда (муниципаль хокукый актларда) билгеләнгән башка вәкаләтләрне башкара.

## 9 статья. Район бюджеты керемнәре

Район бюджеты керемнәре Россия Федерациясенең бюджет законнары, салымнар һәм җыемнар турындагы законнар һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнар нигезендә формалаша.

## 10 статья. Район бюджеты чыгымнары

Район бюджеты чыгымнарын формалаштыру федераль дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән, Россия Федерациясе законнары, шартнамәләр һәм килешүләр буенча чираттагы финанс елында (чираттагы финанс елында һәм план чорында) тиешле бюджетлар акчалары исәбеннән үтәлергә тиешле вәкаләтләрен бүлешүгә бәйле чыгым йөкләмәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен финанслауга Район бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очраклардан тыш, рөхсәт ителми.

Районга тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен өстәмә финанслауга Район бюджетының чыгымнарын гамәлгә ашыру гамәлдәге законнар һәм (яки) Район Советы карарлары нигезендә башкарыла.

## 11 статья. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтүләр сатып алу

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

2. Муниципаль контрактлар, 11.3 статьяда билгеләнгән очраклардан тыш, бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә төзелә һәм түләнә.

3. Әгәр муниципаль контракт предметлары булып үтәү циклы дәвамлылыгы, хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып китә торган эшләр башкару, хезмәт күрсәтү торган очракта, Район Башкарма комитетының муниципаль хокукый актларында каралган очракларда, күрсәтелгән актларда билгеләнгән акчалар чикләрендә һәм срокларда, шулай ук Район Башкарма комитетының Район Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә кабул ителә торган башка карарлары нигезендә төзелергә мөмкин.

4. Муниципаль заказчылар аларда бәясе экономияләнгән энергетика ресурслары бәясенең проценты буларак билгеләнгән муниципаль энергосервис шартнамәләрен (контрактларын) бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып киткән вакытка төзергә хокуклы. Мондый шартнамәләр (контрактлар) өчен түләү чыгымнары тиешле энергетика ресурсларын (аларны китерүгә хезмәт күрсәтүләр) түләүгә чыгымнар составында планлаштырыла һәм гамәлгә ашырыла.

## 12 статья. Резерв фонды

Район бюджетының чыгым өлешендә Район Башкарма комитетының резерв фонды төзелә. Резерв фонды күләме чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Район бюджеты турында Район Советы карары белән билгеләнә һәм Район бюджеты чыгымнарының расланган гомуми күләменең өч процентыннан артмаска тиеш.

Район бюджеты составында каралган резерв фондының бюджет ассигнованиеләре Район Башкарма комитеты карары буенча файдаланыла.

Район бюджеты составында каралган резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен куллану тәртибе Район Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

Район башкарма комитеты квартал саен резерв фонды акчаларын тоту турында Район Советына хәбәр итә.

## 13 статья. Район бюджетында каралмаган чыгымнарны гамәлгә ашыру

Әгәр чыгым йөкләмәләренең гамәлдәге төрләре буенча чыгым йөкләмәләрен арттыруны яисә Район тарафыннан үтәлмәгән чыгым йөкләмәләренең яңа төрләрен кертүне күздә тоткан норматив хокукый акт кабул ителсә, күрсәтелгән норматив хокукый актта чыгым йөкләмәләренең яңа төрләрен үтәү чыганакларын һәм тәртибен, шул исәптән кирәк очракта, финанс ресурсларын Район бюджетына чыгым йөкләмәләренең яңа төрләренә тапшыру тәртибен билгели торган нормалар булырга тиеш.

Чыгым йөкләмәләренең яңа төрләрен кабул итүгә бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирү яисә чыгым йөкләмәләренең гамәлдәге төрләрен үтәүгә бюджет

ассигнованиеләрен арттыру чираттагы финанс елы башыннан гына тиешле бюджет ассигнованиеләрен Район бюджеты турындагы карарга кертү шарты белән йә агымдагы финанс елында Район бюджеты турындагы карарга тиешле үзгәрешләр керткәннән соң, Район бюджетына өстәмә керемнәрнең тиешле чыганаклары булганда һәм (яисә) Район бюджетына һәм (яисә) Район бюджеты чыгымнарының аерым статьялары буенча бюджет ассигнованиеләре кыскартылганда гына гамәлгә ашырылырга мөмкин.

### 14 статья. Чыгым йөкләмәләре реестры

Район Финанс-бюджет палатасы чыгым йөкләмәләре реестрын алып барырга бурычлы.

Районның чыгым йөкләмәләре реестры Район Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә алып барыла.

Районның чыгым йөкләмәләре реестры Финанс-бюджет палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырыла.

### 15 статья. Район бюджеты кытлыгы

Чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына) җирле бюджет кытлыгы, әлеге пунктның 15.2 пунктында билгеләнгән чикләүләрне үтәп, Район бюджеты турында карар белән билгеләнә.

Район бюджеты дефициты күләме Район бюджеты керемнәренең, кире кайтарылмый торган түләүләрнең расланган күләмен һәм (яисә) түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре керүне исәпкә алмыйча, расланган гомуми еллык күләменең 5 процентыннан артмаска тиеш.

Район Советының Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары составында тиешле елга бюджет турында карары белән акцияләрдән һәм Район милкендәге капиталда катнашуның бүтән формаларыннан кергән керемнәр һәм (яисә) Район бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча счетларда калган акчаларның кимүе расланган очракта, Район бюджеты дефициты әлеге пунктта билгеләнгән чикләүләрне әлеге керемнәр суммасы һәм Район бюджеты акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны киметү чикләрендә узып китәргә мөмкин.

### 16 статья. Район алдында акчалата йөкләмәләр

1. Район каршындагы акчалата йөкләмәләр буенча бурыч – бурычлы кеше Район каршындагы акчалата бурычлары нигезендә билгеле бер датага түләргә тиеш булган акчалар суммасы.

2. Район каршында акчалата йөкләмәләр буенча таләпләр Районның финанс активларын формалаштыра.

3. Район каршында акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны исәптән төшерү һәм торгызу кагыйдәләре (нигезләре, шартлары һәм тәртибе), Россия Федерациясе Бюджет кодексында каралган очраклардан тыш, Район Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә.

4. Район алдында акчалата йөкләмәләрне (акчалата йөкләмәләр буенча бурычларны) һәм мондый йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итә торган алыш-бирешләрне исәпкә алу, шулай ук күрсәтелгән йөкләмәләр һәм алыш-бирешләр буенча таләпләрнең хокукларын гамәлгә ашыру Россия Федерациясе Бюджет кодексының $^{932}$ статьясындагы 4 пунктында күрсәтелгән тиешле орган яисә Россия Федерациясе Бюджет кодексының $^{932}$ статьясындагы 5 пунктында күрсәтелгән вәкаләтле зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Шартнамәдә башкача билгеләнмәгән очракта, Район алдында акчалата йөкләмәләр тиешле сумманы Район бюджетының бердәм счетына күчерү датасыннан алып үтәлгән булып санала.

## 17 статья. Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

Район бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганаклары составына түбәндәгеләр кертелә:

номиналь хакы Россия Федерациясе валютасында күрсәтелгән муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштырудан кергән акчалар һәм аларны түләүгә юнәлдерелгән акчалар арасындагы аерма;

кредит оешмаларының Россия Федерациясе валютасында Район тарафыннан җәлеп ителгән һәм түләнгән кредитлары арасындагы аерма;

Район тарафыннан Россия Федерациясе валютасында җәлеп ителгән һәм түләнгән Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетлары тарафыннан Район бюджетына бирелгән бюджет кредитлары арасындагы аерма;

тиешле финанс елы дәвамында җирле бюджет акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны үзгәртү;

җирлек бюджеты кытлыгын эчке финанслауның бүтән чыганаклары.

Район бюджеты кытлыгын тышкы финанслауның тэчке чыганаклары составына түбәндәгеләр кертелә:

Район милкендә булган акцияләр сатудан һәм капиталда катнашуның башка формаларыннан керемнәр;

Район бюджеты акчалары буенча курс аермасы;

муниципаль гарантияләрне Гарант тарафыннан үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә йә гарантка бенефициарның принципалга карата таләп хокукларына юл куелганда, Россия Федерациясе валютасында Район гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акчалар күләме;

Районның бүтән бурыч йөкләмәләрен түләүгә Россия Федерациясе валютасында җибәрелә торган акчалар күләме;

юридик затларга Район бюджетыннан бирелгән бюджет кредитларын кире кайтарудан алынган акчалар һәм юридик затларга Россия Федерациясе валютасында Район бюджетыннан бирелгән бюджет кредитлары суммасы арасындагы аерма;

Район бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелгән бюджет кредитларын кире кайтарудан алынган акчалар

һәм Район бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары суммасы арасындагы аерма;

Район бюджетының бердәм счетыннан күчерелгән акчалар һәм Район бюджеты акчаларын исәпкә алу буенча бердәм счетта калган акчалар белән идарә итү операцияләре үткәргәндә Район бюджетының бердәм счетына күчерелгән акчалар арасындагы аерма.

Агымдагы финанс елы башына Район бюджеты акчаларының калган өлешләре муниципаль юл фондының хисап финанс елында файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре күләмендә агымдагы финанс елында муниципаль юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен арттыруга җибәрелә, шулай ук Район Советының хокукый акты белән билгеләнә торган күләмдә агымдагы финанс елында вакытлыча касса аермаларын каплауга һәм әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә хисап финанс елында түләнергә тиешле товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Район исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә бюджет ассигнованиеләрен арттыруга; юридик затларга Район бюджеты турындагы карарда каралган очракларда файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калган суммасыннан артмаган күләмдә субсидияләр бирү өчен, хисап финанс елында субсидияләр бирү субсидияләр алучыларның күрсәтелгән субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булган акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә гамәлгә ашырылган бюджет ассигнованиеләре н арттыруга җибәрелә.

Район бюджеты кытлыгын тышкы финанслауның тышкы чыганаклары составына түбәндәгеләр кертелә:

чит ил валютасында Россия Федерациясеннән җәлеп ителгән һәм Район тарафыннан түләнгән максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында бирелгән бюджет кредитлары арасындагы аерма;

муниципаль гарантияләрне Гарант тарафыннан үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә, максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясе тарафыннан бирелгән чит ил валютасында муниципаль гарантияләрне үтәүгә җибәрелә торган акчалар күләме»;

## 18 статья. Районның муниципаль бурычы структурасы.

Районның бурыч йөкләмәләре түбәндәгеләр буенча йөкләмәләр рәвешендә булырга мөмкин;

1) Районның кыйммәтле кәгазьләре (муниципаль кыйммәтле кәгазьләр);

2) Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җирле бюджетка җәлеп ителгән бюджет кредитлары;

3) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясеннән чит ил валютасында җәлеп ителгән бюджет кредитлары;

4) Район тарафыннан кредит оешмаларыннан Россия Федерациясе валютасында җәлеп ителгән кредитлар;

5) Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Район гарантияләре (муниципаль гарантияләр);

6) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясе чит ил валютасында бирелгән муниципаль гарантияләр;

7) Россия Федерациясе Бюджет кодексы гамәлгә кергәнче барлыкка килгән һәм муниципаль бурычка кертелгән бүтән бурыч йөкләмәләре буенча.

Муниципаль бурыч күләменә кертелә:

1) муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча бурычның номиналь суммасы;

2) Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җирле бюджетка җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

3) Район тарафыннан кредит оешмаларыннан җәлеп ителгән кредитлар буенча төп бурыч күләме;

4) муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме;

5) Районның түләнмәгән бүтән бурыч йөкләмәләре күләме.

Муниципаль эчке бурыч күләменә кертелә:

1) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча бурычның номиналь суммасы;

2) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан җирле бюджетка җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

3) йөкләмәләре Россия Федерациясе валютасында белдерелгән кредит оешмаларыннан Район тарафыннан җәлеп ителгән кредитлар буенча төп бурыч күләме;

4) Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме;

5) Россия Федерациясе валютасында Районның түләнмәгән бүтән бурыч йөкләмәләре күләме.

Муниципаль тышкы бурыч күләменә кертелә:

1) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Россия Федерациясеннән Район тарафыннан җәлеп ителгән чит ил валютасындагы бюджет кредитлары буенча төп бурыч күләме;

2) максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Район тарафыннан бирелгән чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләр күләме.

**19 статья. Россия Федерациясе валютасында белдерелгән Районның бурыч йөкләмәләрен туктату һәм аларны муниципаль бурычтан төшереп калдыру**

Әгәр Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәсе муниципаль бурыч йөкләмәләре шартларында каралган түләү датасыннан соң килүче датадан соң өч ел эчендә түләүгә куелмаган (кредитор тарафыннан билгеле бер шартлар һәм Районның муниципаль хокукый актлары белән гамәл кылылмаган) булса, күрсәтелгән йөкләмә тулысынча туктатылган дип санала һәм, әгәр Районның вәкиллекле органының муниципаль хокукый актларында башкасы каралмаган булса, муниципаль бурычтан төшереп калдырыла.

Муниципаль гарантияләр буенча Районның Россия Федерациясе валютасында бурыч йөкләмәләре муниципаль гарантияләрне туктатуга нигез булып торучы вакыйгалар (шартлар) туганда тулысынча туктатылган дип санала, һәм күрсәтелгән вакыйгалар (шартлар) башлану (килеп чыгу турында белешмәләр алу) белән муниципаль бурычтан төшереп калдырыла.

2. Җирле администрация, әлеге статьяның 1 пунктындагы беренче абзацында күрсәтелгән сроклар үткәннән соң, Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәләрен муниципаль бурычтан төшереп калдыру турында муниципаль хокукый акт чыгара.

3. Муниципаль бурычтан төшереп калдыру Россия Федерациясе валютасында белдерелгән төшереп калдырыла торган муниципаль бурыч йөкләмәләре төрләре буенча муниципаль бурыч күләмен, җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларында төшереп калдыру суммасын чагылдырмыйча гына, аларны төшереп калдыру суммасына киметү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге статьяның 1 пунктындагы беренче абзацының, 2 һәм 3 пунктларының гамәлдә булуы кредит килешүләре буенча йөкләмәләргә, Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм башка муниципаль берәмлекләр алдында муниципаль бурыч йөкләмәләренә кагылмый.

5. Муниципаль бурычтан реструктурлаштырылган, шулай ук түләнгән (сатып алынган) муниципаль бурыч йөкләмәләрен төшереп калдыру Россия Федерациясе Бюджет кодексының 105 һәм 113 статьялары нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

6. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне түләү датасы җиткәнчегә кадәр эмиссия шартлары нигезендә эмитацияләнгән орган тарафыннан тулы күләмдә сатып алынган (алмашу яисә Россия Федерациясе законнарында каралган башка операцияләр нәтиҗәсендә алынган) муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне чыгару күрсәтелгән орган карары буенча вакытыннан алда түләнгән дип танылырга мөмкин.

Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмитенты аларны түләү датасы җиткәнчегә кадәр сатып алынган (алмашу яисә Россия Федерациясе законнарында каралган башка операцияләр нәтиҗәсендә алынган) ул җитештергән муниципаль кыйммәтле кәгазьләр буенча йөкләмәләрне үтәлгән дип танырга хокуклы

**20 статья. Муниципаль эчке һәм тышкы бурычның югары чикләре һәм Районның бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләренең иң чик кыйммәтләре**

1. Җирле бюджет турындагы карар белән чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына (чираттагы финанс елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына) торышы буенча муниципаль эчке бурычның, муниципаль тышкы бурычның (Районның чит ил валютасындагы йөкләмәләре булганда) иң югары чикләре, шул исәптән Россия Федерациясе валютасындагы муниципаль гарантияләр, чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр (Районның чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр буенча йөкләмәләре булганда) буенча бурычның иң югары чиген күрсәтеп билгеләнә.

2. Муниципаль эчке бурычның, муниципаль тышкы бурычның иң югары чикләре (Районның чит ил валютасындагы йөкләмәләре булганда) әлеге статьяның 4 һәм 5 пунктларында билгеләнгән чикләүләрне үтәгәндә билгеләнә.

3. Муниципаль бурыч күләме, кире кайтарылмый торган түләүләрнең расланган күләмен һәм (яисә) физик затлар кеременә салымнан күчерүләрнең (отчисления) өстәмә нормативлары буенча салым керемнәре кертемнәрен исәпкә алмыйча, чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турында карар белән расланган җирле бюджет керемнәренең гомуми күләменнән артмаска тиеш.

4. Муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме, түбәндәге таләпләрне үтәгәндә, җирле бюджет турындагы карар белән раслана:

1) чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме өлеше чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турындагы карар белән расланган тиешле бюджет чыгымнарының гомуми күләменең 10 процентыннан артмаска тиеш, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнар күләменнән тыш;

2) чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) чираттагы финанс елының 1 гыйнварына барлыкка килгән муниципаль бурычны түләү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча түләүләрнең еллык суммасы чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турында карар белән расланган җирле бюджетның салым, салым булмаган керемнәренең һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан дотацияләрнең гомуми күләменнән 20 проценттан артмаска тиеш; күрсәтелгән нисбәтне исәпләгәндә, Чираттагы финанс елы һәм план чорының һәр елы өчен килә торган елның 1 гыйнварыннан соң килә торган түләү вакыты белән бурыч йөкләмәләрен вакытыннан алда түләүгә җибәрелә торган түләүләр суммасы исәпкә алынмый.

## 21 статья. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр

1. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр дип Район исеменнән чыгарылган кыйммәтле кәгазьләр танала.

2. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмитенты булып Район Уставы белән муниципаль бурыч алулар башкару хокукына ия булган җирле администрация тора.

3. Район тарафыннан чыгарылырга мөмкин булган муниципаль кыйммәтле кәгазьләр төрләре һәм аларның эмиссиясе, һәм алар белән эш итү тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.

**22 статья. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр урнаштыруның чик күләмнәре**

Чираттагы финанс елына һәм план чорының һәр елына (чираттагы финанс елына) муниципаль кыйммәтле кәгазьләрнең номиналь хакы буенча иң чик күләме тиешле бюджет турында карар белән билгеләнгән муниципаль эчке бурычның югары чикләре нигезендә Район Советы тарафыннан билгеләнә.

**23 статья. Муниципаль гарантияләр**

1. Муниципаль гарантия принципалның бенефициар каршында килешүдән яки башка алыш-бирештән (төп йөкләмәдән) килеп чыккан акчалата йөкләмәләрен тиешенчә үтәүне тәэмин итә.

2. Муниципаль гарантия принципал йөкләмәләрен вакытыннан алда үтәүне, шул исәптән принципалга аларны вакытыннан алда башкару турында таләпләр куелган очракта яисә принципал йөкләмәләрен үтәү срогы килеп җиткән дип санала торган вакыйгалар (хәлләр) туган очракта тәэмин итми.

3. Муниципаль гарантиянең язма формасы мәҗбүри булып тора.

4. Муниципаль гарантия төп йөкләмә суммасы билдерелгән валютада бирелә.

5. Муниципаль гарантия буенча гарант гарантия суммасы чикләрендә принципалның үзенә тәэмин ителгән йөкләмәсе буенча субсидиар җаваплылык тота.

6. Муниципаль гарантиядә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гарант исеме (тиешле гавами-хокукый берәмлек – Район) һәм гарант исеменнән гарантия бирүче орган исеме;

2) бенефициар атамасы;

3) принципалның исеме;

4) тәэмин ителешенә гарантия бирелә торган йөкләмә (төп йөкләмәнең исемен, төзү датасын һәм номерын (булган очракта), төп йөкләмәнең гамәлдә булу вакытын яисә аның буенча йөкләмәләрне үтәү срогын, якларның атамаларын, төп йөкләмәнең башка мөһим шартларын күрсәтеп);

5) гарантия буенча гарант йөкләмәләре күләме һәм гарантиянең иң чик суммасы;

6) гарантия бирү нигезләре;

7) гарантиянең үз көченә керү датасы яки гарантия үз көченә керә торган вакыйга (шарт);

8) гарантиянең гамәлдә булу срогы;

9) гарантия очрагын билгеләү, гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбен кую вакыты һәм тәртибе;

10) гарантияне кире алу нигезләре;

11) гарант тарафыннан гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү тәртибе;

12) гарантиянең тулы күләмендә яисә нинди дә булса өлешендә үтәгәндә, принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләрен тулы күләмдә яисә нинди дә булса өлешендә үтәгәндә (башка нигезләр буенча туктатканда) һәм гарантиядә билгеләнгән башка очракларда гарантия суммасын киметү нигезләре;

13) гарантияне туктату нигезләре;

14) гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый торган төп йөкләмә шартлары;

15) гарант тарафыннан бенефициарга муниципаль гарантия буенча түләнгән акчаларны каплау турында принципалга карата гарантның таләбе булу яисә булмау (гарантның принципалга карата регресс таләбе, регресс) ;

16) гарантиянең башка шартлары, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексы, гарантның норматив хокукый актлары, гарант исеменнән гарантия бирүче орган актлары белән билгеләнгән белешмәләр.

7. Принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган муниципаль гарантия белән акцияләренең (өлешләренең) 100 проценты Район (гарант) карамагында булган хуҗалык җәмгыяте, мөлкәте Район (гарант) милкендә булган муниципаль унитар предприятиенең йөкләмәләре генә тәэмин ителә ала.

8. Муниципаль гарантиянең үз көченә керүе календарь дата белән яисә гарантиядә күрсәтелгән билгеле бер вакыйга (шартлар) башлану белән билгеләнә.

9. Гарант бенефициарның алдан язма ризалыгыннан башка муниципаль гарантия шартларын үзгәртергә хокуклы түгел.

10. Муниципаль гарантия буенча бенефициарның гарантка карата таләп хокуклары гарантның алдан язмача ризалыгыннан башка тапшырылырга (башка нигезләр буенча күчәргә) мөмкин түгел, яңа хуҗага (сатып алучыга) алар буенча принципал (эмитент) йөкләмәләрен үтәү муниципаль гарантия белән тәэмин ителә торган облигацияләргә хокуклар күчүгә бәйле рәвештә күрсәтелгән таләп хокукларын кыйммәтле кәгазьләр турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырудан (күчү) тыш.

11. Кредит (заем, шул исәптән облигацион) буенча принципалның йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүче муниципаль гарантия гарант тарафыннан түбәндәге очракларда гына кире алынырга тиеш:

1) муниципаль гарантиядә күрсәтелгән гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый торган төп йөкләмә шартларын гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәртү;

2) муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән кредит (заем, шул исәптән облигацион) акчаларыннан максатчан файдаланмау.

12. Бенефициарның муниципаль гарантия буенча акча түләү турындагы таләбе (гарантияне үтәү турында бенефициар таләбе) гарантка гарантиядә билгеләнгән очракта гына (гарантия очрагы килеп туганда) бирелергә мөмкин. Гарантияне үтәү турында бенефициар таләбе гарантиядә билгеләнгән тәртиптә, гарантиядә күрсәтелгән документларны кушып, гарантка язмача тапшырылырга тиеш.

13. Бенефициар муниципаль гарантия һәм муниципаль гарантия бирү турында шартнамә белән билгеләнгән срогыннан алда, шул исәптән, принципалның гарантия белән тәэмин ителгән йөкләмәләрен үтәү срогы килеп җиткән дип исәпләнә торган вакыйгалар (шартлар) туган очракта гарантияне үтәү турында таләпләр куярга хокуклы түгел.

14. Гарант гарантия үтәлеше турында бенефициарның таләп кую турында принципалга хәбәр итәргә һәм принципалга таләпнең күчермәсен тапшырырга бурычлы.

Гарант муниципаль гарантиядә билгеләнгән срокта гарантияне үтәү турында бенефициар таләбен таләпнең һәм аңа кушып бирелгән документларның нигезлелеге һәм гарантия шартларына туры килү-килмәве предметы буларак күрсәтелгән таләпкә кушымта итеп бирелгән документлар белән бергә карарга тиеш.

16. Гарантияне үтәү турында бенефициар таләбе һәм аңа кушып бирелгән документлар нигезсез һәм (яисә) гарантия шартларына туры килми дип таныла һәм гарант бенефициарга түбәндәге очракларда аның таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тарта:

1) таләп һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар гарантка гарантиянең бирелгән срогы (гарантиянең гамәлдә булу срогы) тәмамланганнан соң тапшырылган;

2) таләп һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар гарантка гарантиядә билгеләнгән тәртипне бозып тапшырылган;

3) таләп һәм (яки) аңа кушып бирелгән документлар гарантия шартларына туры килми;

4) бенефициар принципалның принципал һәм (яки) өченче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән принципал йөкләмәләрен тиешенчә үтәүдән баш тарта;

5) гарантиядә билгеләнгән башка очракларда.

17. Гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбе һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар нигезсез һәм (яисә) муниципаль гарантия шартларына туры килми дип танылган очракта, гарант бенефициарга аның таләпләрен канәгатьләндерүдән баш тартуы турында хәбәр итәргә бурычлы.

18. Гарант бенефициар таләбенә каршы принципал тәкъдим итәргә мөмкин булган каршылыклар белдерергә хокуклы. Гарант, принципал алардан баш тарткан яки үз бурычын таныган очракта да, әлеге каршылыкларга хокукын югалтмый.

19. Гарантия үтәлеше турында бенефициар таләбе һәм (яисә) аңа кушып бирелгән документлар нигезле һәм муниципаль гарантия шартларына туры килә дип танылган очракта, гарант гарантия белән билгеләнгән вакытта гарантия буенча йөкләмәне үтәргә тиеш.

20. Гарантның бенефициар алдындагы муниципаль гарантиядә каралган бурычы принципалның гарантия белән тәэмин ителгән срогы чыккан йөкләмәләре күләмендә, әмма гарантия суммасыннан да артмаган күләмдә акча түләү белән чикләнә.

21. Муниципаль гарантия буенча бенефициар каршында гарантның бурычы туктатыла:

1) гарант тарафыннан бенефициарга гарантиядә билгеләнгән күләмдә акча түләү белән;

2) гарантиядә ул бирелгән билгеле бер вакыт (гарантиянең гамәлдә булу срогы) үткәннән соң;

3) принципал һәм (яисә) өченче затлар тарафыннан гарантия белән тәэмин ителгән принципал йөкләмәләрен үтәү йә принципалның күрсәтелгән йөкләмәләре башка нигезләр буенча туктатылган очракта (бенефициар тарафыннан гарантка һәм (яисә) судка бирелгән гарантия үтәлеше турында гарантка карата таләпләр булуга карамастан);

4) бенефициарның гарантка аны кире кайтару юлы белән гарантия буенча үз хокукларыннан баш тартуы һәм (яисә) бенефициарның гарантны гарантия буенча үз вазыйфаларыннан азат итү турында язма гаризасын бирү нәтиҗәсендә, мондый гарантия буенча бенефициарлар фактта булмаганда һәм киләчәктә алар барлыкка килү өчен нигезләр булмаганда, принципал тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 115 статьясында каралган гарантияне гарантка кире кайтару нәтиҗәсендә;

5) әгәр ангы тәэмин итүгә гарантия бирелгән принципал йөкләмәсе билгеләнгән срокта барлыкка килмәсә;

6) төп йөкләмәне (шул исәптән, бенефициар гарантка һәм (яки) судка гарантияне үтәү турындагы гарантка таләп биргәннән соң, принципалны һәм (яки) бенефициарны бетерү белән бәйле рәвештә) туктату яисә аны гамәлдә булмаган алыш-биреш дип тану белән;

7) гарантия буенча бенефициарның гарантка карата таләп хокукларын, төп бурыч буенча хокук һәм (яки) бурычларны бенефициар башка нигезләр буенча гарантның алдан язма ризалыгыннан башка бүтән затка тапшырган яки икенче затка күчкән очракт (яңа хуҗага (сатып алучыга) алар буенча принципал (эмитент) йөкләмәләрен үтәү муниципаль гарантия белән тәэмин итеlә торган облигацияләргә хокуклар күчүгә бәйле рәвештә күрсәтелгән таләп хокукларын (хокук һәм бурычлар) кыйммәтле кәгазьләр турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшырудан (күчү) тыш).

8) принципал тарафыннан төп бурыч буенча принципалга караган хокуклар һәм (яисә) бурычлар (долг) гарантның алдан язма ризалыгыннан башка бүтән затка тапшырылган яисә башка нигезләр буенча икенче затка күчкән очракта;

9) , гарантиядә күрсәтелгән очракларда һәм нигезләр буенча гарантияне кире алу нәтиҗәсендә;

10) гарантиядә билгеләнгән башка очракларда.

22. Гарантның аның буенча йөкләмәләре туктатылганнан соң бенефициарның гарантияне тотып калуы бенефициарда күрсәтелгән гарантия буенча нинди дә булса хокуклар сакламый.

23. Муниципаль гарантияне туктату турында мәгълүм булган гарант бу хакта бенефициарга һәм принципалга хәбәр итәргә тиеш.

Муниципаль гарантияне чакыртып алу яисә туктатуга китерә торган хәлләр килеп чыгу турында мәгълүм булган Бенефициар һәм принципал бу хакта гарантка хәбәр итәргә тиеш.

24. Әгәр гарант тарафыннан муниципаль гарантияне үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китерсә йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка юл куелуга бәйле булса, мондый муниципаль гарантияне үтәү өчен акчалар тиешле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларында исәпкә алына, ә мондый муниципаль гарантия буенча йөкләмәләрне үтәү бюджет кредиты бирү буларак карала.

25. Әгәр гарант тарафыннан муниципаль гарантияне үтәү гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукы барлыкка килүгә китермәсә йә бенефициарның принципалга карата таләбе хокуклары гарантка юл куелуга бәйле булмаса, мондый муниципаль гарантияне үтәү өчен акчалар тиешле бюджет чыгымнарында исәпкә алына.

26. Гарант тарафыннан гарантия буенча йөкләмәләрнең тулы күләмендә яисә нинди дә булса өлешендә үтәү өчен гарант тарафыннан түләнгән акчалар регрессы тәртибендә Гарант тарафыннан алынган акчалар яисә гарантка бенефициарның принципалга Карата таләбе хокукын үтәү йөзеннән Гарант тарафыннан алына торган акчалар бюджет кредитларын кире кайтару буларак чагылдырыла.

27. Муниципаль гарантияләр белән тәэмин ителгән кредитлар һәм заемнар максатчан булырга тиеш. Кредит (заем, облигациядән тыш) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия кредит килешүендә (заем килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне бирү турында килешүдә кредиторның (заем бирүче) үз ягыннан күрсәтелгән кредит (заем) акчаларын максатчан файдалануны контрольдә тоту йөкләмәләрен билгеләгән очракта бирелә.

28. Муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән кредит (заем) акчаларыннан максатсыз файдалану факты ачыкланган очракта, муниципаль гарантия бирү турында килешүдә билгеләнгән йөкләмәләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән очракта, принципал һәм бенефициар Россия Федерациясе законнарында, муниципаль гарантия бирү турындагы килешүдә билгеләнгән җаваплылык тоталар.

29. Бенефициарлар билгесез затлар даирәсе булган йөкләмәләрне тәэмин итүгә бирелә торган муниципаль гарантия үзенчәлекләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.

30. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләр эмиссиясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән йөкләмәләр буенча муниципаль гарантияләрне бирү һәм үтәү үзенчәлекләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы белән билгеләнә.

31. Муниципаль гарантияләрне бирү тәртибе һәм шартлары Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның нигезендә кабул ителгән әлеге карар белән билгеләнә.

## 24 статья. Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр программасы

1. Россия Федерациясе валютасындагы муниципаль гарантияләр программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында бирелә торган муниципаль гарантияләрнең түбәндәге белешмәләр күрсәтелгән Россия Федерациясе валютасындагы исемлегеннән гыйбарәт:

1) гарантияләүнең һәр юнәлеше (максатлары), категорияләре (төркемнәре) һәм (яисә) принципаллар исемнәрен күрсәтеп, гарантияләү юнәлешләре (максатлары);

2) гарантияләрнең гомуми күләме;

3) гарантның принципалларга карата регресс таләбе хокукы булу (булмау);

4) гарантияләрне бирү һәм үтәүнең башка шартлары.

2. Россия Федерациясе валютасында белдерелгән йөкләмәләр буенча муниципаль гарантияләр бары тик Россия Федерациясе валютасында гына бирелә.

3. Россия Федерциясе валютасындагы муниципаль гарантияләр программасы бюджет турындагы тиешле карарга кушымта булып тора.»;

**25 статья. Чит ил валютасында муниципаль гарантияләр программасы**

1. Чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында бирелә торган муниципаль гарантияләрнең түбәндәге белешмәләр күрсәтелгән чит ил валютасындагы исемлегеннән гыйбарәт:

1) гарантияләүнең һәр юнәлеше (максатлары), категорияләре (төркемнәре) һәм (яисә) принципаллар исемнәрен күрсәтеп, гарантияләү юнәлешләре (максатлары);

2) гарантияләр һәм алар тарафыннан тәэмин ителә торган йөкләмәләр буенча йөкләмәләр валютасы;

3) гарантияләрнең гомуми күләме;

4) гарантның принципалларга карата регресс таләбе хокукы булу (булмау);

5) гарантияләрне бирү һәм үтәүнең башка шартлары.

2. Муниципаль гарантия муниципаль гарантия белән тәэмин ителә торган йөкләмәләр белдерелгән валютада бирелә һәм үтәлә.

3. Чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр программасы бюджет турындагы тиешле карарга кушымта булып тора

**26 статья. Муниципаль бурыч алулар (заимствования)**

1. Районның муниципаль эчке бурыч алулары дигәндә муниципаль кыйммәтле кәгазьләр урнаштыру юлы белән һәм Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан һәм кредит оешмаларыннан алар буенча Районның Россия Федерациясе валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган кредитлар рәвешендә Район исеменнән җирле бюджетка заем акчаларын җәлеп итү аңлашыла.

2. Районның муниципаль тышкы бурыч алулары дигәндә, Россия Федерациясе тарафыннан максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында Район исеменнән федераль бюджеттан җирле бюджетка алар буенча Районның

Россия Федерациясе алдында чит ил валютасында белдерелгән бурыч йөкләмәләре барлыкка килә торган кредитлар җәлеп итүе аңлашыла.

3. Муниципаль тышкы бурыч алулар чираттагы финанс елына һәм план чорына Россия Федерациясенең Дәүләт тышкы бурыч алулары программасына кертелгән проектларны финанслау максатларында гамәлгә ашырыла.

4. Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Район Уставы нигезендә муниципаль бурыч алуларны гамәлгә ашыру хокукына җирле администрация (Районның башкарма-боеру органы) ия.

5. Муниципаль кыйммәтле кәгазьләрне урнаштыру Район тарафыннан түбәндәге шартларны үтәгәндә гамәлгә ашырыла:

1) Районның бурыч йөкләмәләре буенча кичектерелгән бурычлары булмау;

2) Район тарафыннан исемлекләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган рейтинг гамәлләрен тормышка ашыручы бер яисә берничә юридик заттан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган дәрәҗәдән дә ким булмаган кредит рейтингы алынган.

6. Район, аны Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы уртача дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә керткән очракта, муниципаль бурыч алулар башкарырга, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясындагы 5 пунктында каралган Районның бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләренең зурлыгын Районны бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә кертергә мөмкинлек бирә торган дәрәҗәләргә кадәр арттыруга китерә торган күләмнәрдә муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы түгел.

7. Район, аны Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы уртача дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә керткән очракта, муниципаль бурыч алулар башкарырга, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән муниципаль эчке һәм тышкы бурыч алулар программаларын, чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль гарантияләр программаларын, шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләрне килештергән очракта гына муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы.

8. Район, аны Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә керткән очракта, муниципаль бурыч алулар башкарырга, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясындагы 5 пунктында каралган Районның бурыч тотрыклылыгы күрсәткечләренең зурлыгын арттыруга китерә торган күләмнәрдә муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы түгел.

9. Район, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә кергән очракта, кредит оешмаларыннан кредитлар рәвешендә һәм бары тик Районның бурыч

йөкләмәләрен рефинанслау максатларында гына Районның кыйммәтле кәгазьләрен урнаштыру юлы белән, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясындагы 9 пунктында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясындагы 7 пунктында каралган Районның түләү сәләтен торгызу планы кысаларында Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан максатчан бюджет кредитлары формасында бирелгән муниципаль эчке бурыч алулар башкарырга хокуклы.

10. Район, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән булган заемчылар төркеменә кергән очракта, муниципаль тышкы бурыч алулар башкарырга һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында бирергә хокуклы түгел.

11. Район, аны Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 31 статьясы нигезендә бурыч тотрыклылыгы түбән дәрәҗәдә булган заемчылар төркеменә керткән очракта, муниципаль эчке бурыч алулар башкарырга, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән муниципаль эчке бурыч алулар, чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр программаларын, шулай ук күрсәтелгән программаларга үзгәрешләрне килештергән очракта гына Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр бирергә хокуклы.

12. Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 107 статьясындагы 9 пунктында каралган Районга түләү мөмкинлеген торгызу планы кысаларында бирелгән максатчан бюджет кредитлары буенча Район йөкләмәләренә реструктуризация үткәрү рөхсәт ителми.

**27 статья. Район тарафыннан чит ил валютасында бурыч алулар һәм гарантияләр бирүне башкару үзенчәлекләре.**

1. Район Россия Федерациясеннән чит ил валютасында бурыч алулар башкарырга, Россия Федерациясенә чит ил валютасында өченче затлар йөкләмәләре буенча гарантияләрне бары тик җәлеп ителгән максатчан чит ил кредитларын Россия Федерациясе тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 статьясындагы 25 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып куллану кысаларында гына бирергә хокуклы.

**28 статья. Муниципаль бурыч алуларның иң чик күләме.**

1. Тиешле финанс елына муниципаль бурыч алуларның иң чик күләме дигәндә тиешле финанс елына муниципаль эчке һәм тышкы бурыч алулар программалары буенча җирле бюджетка акча җәлеп итүнең җыелма күләме аңлашыла.

2. Җирле бюджетка акча җәлеп итү күләмнәре чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке һәм тышкы бурыч алулар программалары белән билгеләнә һәм тиешле финанс елында акчаларны

җәлеп итүнең гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга җибәрелә торган акчаларның гомуми суммасыннан һәм тиешле финанс елына җирле бюджет турында карар белән расланган Районның бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 103 һәм 104 статьялары нигезләмәләрен исәпкә алып, артмаска тиеш.

3. Хисап финанс елында Район бурыч алуларының гомуми суммасы җирле бюджет кытлыгын финанслауга юнәлдерелгән акчаларның гомуми суммасыннан һәм хисап финанс елы нәтиҗәләре буенча агвымдагы елныж 1 гыйнварына барлыкка килгән Районның бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәреннән артып киткән очракта, җирле бюджет акчаларының әлеге артыклык суммасында калган өлешләре, агымдагы финанс елына бурыч алуларның иң чик күләмен кыскартып, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96 статьясында каралган максатларга юнәлдерелергә тиеш.

### 29 статья. Муниципаль эчке бурыч алулар программасы.

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке бурыч алулар программасы чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) гамәлгә ашырыла торган һәм (яисә) түләнә торган тиешле бурыч йөкләмәләре төрләре буенча муниципаль эчке бурыч алулар исемлегеннән гыйбарәт.

2. Муниципаль эчке бурыч алулар программасы белән түбәндәгеләр билгеләнә:

1) җирле бюджетка акча җәлеп итү күләме һәм чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) тиешле бурыч йөкләмәләре төрләре буенча муниципаль эчке бурыч алуларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган бурыч йөкләмәләрен түләүнең иң чик сроклары;

2) тиешле бурыч йөкләмәләре төрләре буенча Россия Федерациясе валютасында белдерелгән муниципаль бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәре.

3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль эчке бурыч алулар программасы чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) тиешле бюджет турындагы карарга кушымта булып тора.

4. Россия Федерациясе Бюджет кодексының 105 статьясы нигезендә муниципаль эчке бурычны үткәрү муниципаль эчке бурыч алулар программасында чагылыш тапмый.

### 30 статья. Муниципаль тышкы бурыч алулар программасы

1. Чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль тышкы бурыч алулар программасы чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) чмаксатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында федераль бюджеттан чит ил валютасында җирле бюджетка җәлеп ителә торган һәм (яки) чит ил валютасында түләнелә торган бюджет кредитлары исемлегеннән гыйбарәт.

2. Муниципаль тышкы бурыч алулар программасы белән түбәндәгеләр билгеләнә:

1) җирле бюджетка акча җәлеп итү күләме һәм максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында) федераль бюджеттан чит ил валютасында җирле бюджетка җәлеп ителә торган бюджет кредитлары буенча барлыкка килә торган бурыч йөкләмәләрен каплау сроклары;

2) чираттагы финанс елында һәм план чорында (чираттагы финанс елында), максатчан чит ил кредитларын куллану кысаларында федераль бюджеттан чит ил валютасында җирле бюджетка җәлеп ителгән бюджет кредитлары буенча барлыкка килгән бурыч йөкләмәләрен түләү күләме.

3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) муниципаль тышкы бурыч алулар программасы чираттагы финанс елына һәм план чорына (чираттагы финанс елына) җирле бюджет турындагы карарга кушымта булып тора.

## 31 статья. Муниципаль бурыч кенәгәсе

1. Муниципаль бурыч кенәгәсен алып бару Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан башкарыла.

Бурыч йөкләмәләре турындагы мәгълүмат әлеге орган тарафыннан муниципаль бурыч кенәгәсенә тиешле йөкләмә барлыкка килгән мизгелдәнбиш эш көненнән дә артмаган срокта кертелә.

2. Муниципаль бурыч кенәгәсенә әлеге йөкләмәләр төрләре буенча Районның бурыч йөкләмәләре күләме, аларның барлыкка килү һәм тулысынча һәм өлешчә үтәлү датасы, йөкләмәләрне тәэмин итү формалары турында белешмәләр, шулай ук составы, аны муниципаль бурыч кенәгәсенә кертү тәртибе һәм вакыты Район Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә торган башка мәгълүмат кертелә.

Муниципаль бурыч кенәгәсендә Районның бурыч йөкләмәләрен исәпкә алу, бюджет законнарында билгеләнгән тышкы һәм эчке бурыч билгеләмәләреннән чыгып, аның барлыкка килүе вакытында акчалата йөкләмә билгеләнгән бурыч валютасында гамәлгә ашырыла. Районның муниципаль бурыч кенәгәсендә шул исәптән муниципаль бурыч йөкләмәләрен үтәү буенча кичектерелгән бурычлар турында мәгълүмат исәпкә алына.

3. Муниципаль бурыч кенәгәсендә чагылдырылган Районның бурыч йөкләмәләре турында мәгълүмат әлеге орган тарафыннан билгеләнгән күләмдә, тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырылырга тиеш.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырылган бурыч йөкләмәләре турындагы белешмәләрнең дөреслеге өчен Район Финанс-бюджет палатасы җавап бирә.

## 32 статья. Район бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертларның формалары.

Район бюджетыннан бюджетара трансфертлар түбәндәге формаларда бирелә:

җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Район бюджетыннан дотацияләр;

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 133 һәм 140 статьяларында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.6 статьясында билгеләнгән очракларда, Район бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына субвенцияләр

муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр;

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясында билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр;

башка бюджетара трансфертлар.

Район бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар (төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бюджетара трансфертлардан тыш) шәһәр, авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан Район бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрендә билгеләнгән шартларны үтәгәндә бирелә.

Татарстан Республикасы бюджеты, шул исәптән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль Районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән бирелә торган шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына Район бюджетыннан бюджетара трансфертлар (субвенцияләрдән тыш) Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44 статьясында каралган җирле бюджетларга Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар бирүнең төп шартларын шәһәр, авыл җирлекләренең тиешле җирле үзидарә органнары тарафыннан үтәү шарты белән бирелә.

Җирле бюджетлардан финанс ягыннан тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр, субвенцияләр һәм максатчан билгеләнеше булган башка бюджетара трансфертлар тора торган бюджетара трансфертлар бирү максатлары, тәртибе һәм шартлары, Татарстан Республикасы законнары һәм (яисә) башка норматив хокукый актлары нигезендә кабул ителгән Район Советы карарлары белән билгеләнә.

**33 статья. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Район бюджетыннан дотацияләр бирү тәртибе**

1. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Район бюджетыннан дотацияләр Район составына керүче җирлекләргә Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләре нигезендә кабул ителә торган Район Советы карарлары нигезендә бирелә.

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Район бюджетыннан дотацияләрнең гомуми күләме ел саен чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Район бюджеты проектын төзегәндә Район составына керүче җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә җирлекләр

бюджетына бирелә торган һәм җирлекләрнең исәп-хисап бюджет тәэмин ителешен тигезләү критериенә ирешү зарурлыгыннан чыгып, җирлекләрнең суммар ихтыяҗларын һәм керем мөмкинлекләрен бәяләүдәге аерманы исәпкә алып исәпләнелә торган дотацияләрнең һәм җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.1 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган дотацияләрнең суммар күләме буларак билгеләнә.

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Район бюджетыннан дотацияләрне, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.1 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган дотацияләрдән тыш, муниципаль берәмлекләр арасында бүлү Татарстан Республикасы Бюджет кодексына 12 нче кушымта белән билгеләнгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Район бюджетыннан дотацияләр күләме һәм бүлү чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Район бюджеты турында Район Советы карары белән раслана.

Район бюджеты проекты Чираттагы финанс елына һәм план чорына расланган очракта, план чорына Район бюджетыннан бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләрнең шәһәр, авыл җирлекләре арасында бүленмәгән күләмен план чорының беренче елына расланган күрсәтелгән дотацияләрнең гомуми күләменнән 20 проценттан да артмаган һәм план чорының икенче елына расланган күрсәтелгән дотацияләрнең гомуми күләменнән 20 проценттан да артмаган күләмдә раслау *рөхсәт ителә.*

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Район бюджетыннан дотацияләрне, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.1 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган дотацияләрдән тыш, хисаплы бюджет тәэмин ителеше Районның шәһәр һәм авыл җирлекләренең хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие буларак билгеләнгән дәрәҗәдән артмый торган шәһәр һәм авыл җирлекләренә бирелә.

Җирлекләрнең исәп-хисап бюджет тәэмин ителеше, салым базасыннан (салым потенциалыннан) чыгып, шәһәр һәм авыл җирлеге бюджеты тарафыннан алынырга мөмкин булган бер кешегә салым керемнәре нисбәте белән һәм, бер кешегә исәпләгәндә муниципаль хезмәтләр күрсәтү бәясенә тәэсир итә торган халык структурасындагы, социаль-икътисадый, климатик, географик һәм башка объектив факторлар һәм шартлардагы аермаларны исәпкә алып билгеләнә.

Хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсе шәһәр һәм авыл җирлекләре буенча шәһәр һәм авыл җирлекләренең салым керемнәре чагыштырмасын, бюджет хезмәтләре исемлеген җирлекләр буенча бер кешегә исәпләгәндә муниципаль хезмәтләр күрсәтү бәясенә тәэсир итә торган факторларны һәм шартларны характерлый торган күрсәткечләрне тасвирлый торган бердәм методика буенча билгеләнә һәм шәһәр һәм авыл җирлекләре өчен аерым билгеләнә ала.

Җирлекләрнең хисаплы бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен билгеләгәндә хисап чорына факттагы керемнәр һәм чыгымнар күрсәткечләрен һәм (яисә) аерым

җирлекләрнең фаразлана торган керемнәре һәм чыгымнары күрсәткечләрен куллану рөхсәт ителми.

4. Әлеге статьяның 3 пунктында каралган дотацияләр бирелгән очракта, Районның финанс органы җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Район бюджетыннан дотацияләр алучы муниципаль берәмлекләрнең җирле администрация башлыклары (башкарма-бүлү органнары җитәкчеләре) белән җирлекнең муниципаль финансларын социаль-икътисадый үстерү һәм савыктыру буенча чаралар күздә тотыла торган килешүләр төзергә хокуклы.

Килешүләр төзү тәртибе, сроклары һәм әлеге пунктта күрсәтелгән килешүләргә таләпләр Районның җирле администрациясе (башкарма-боеру органы) тарафыннан билгеләнә.

**34 статья. Татарстан Республикасы бюджетына Район бюджетыннан субсидияләр**

1. Район бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясында билгеләнгән тәртиптә бирелә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бюджетара субсидияләр Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы нигезендә Район бюджетында карала.

**35 статья. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына Район бюджетыннан субсидияләр**

1. Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы таләпләренә туры китереп кабул ителә торган Район Советы карарларында каралган очракларда һәм тәртиптә башка муниципаль берәмлекләр бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Район бюджетыннан субсидияләр бирелергә мөмкин.

2. Әлеге статьяда күрсәтелгән субсидияләрне бирү максатлары һәм шартлары Район Советы карары белән билгеләнгән тәртиптә җирле администрацияләр арасында төзелгән килешүләр белән билгеләнә.

**36 статья. Район бюджетыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм аларга тиң Татарстан Республикасы законнары таләпләренә туры китереп кабул ителә торган Район Советы карарларында каралган очракта һәм тәртиптә шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына Район бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар, шул исәптән төзелгән килешүләр нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр өлешен гамәлгә ашыруга бюджетара трансфертлар бирелергә мөмкин.

## 2 бүлек РАЙОН БЮДЖЕТЫ ПРОЕКТЫН ТӨЗҮ

## 37 статья. Гомуми нигезләмәләр

1. Чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Район бюджеты проекты, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм аның таләпләрен үтәп кабул ителгән Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Район Уставы һәм әлеге Нигезләмә нигезендә, Район Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә һәм срокларда төзелә.

2. Бюджет проекты Районның социаль-икътисади үсеш фаразы, муниципаль программалар, Районның чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре нигезендә төзелә.

3. Район бюджеты проекты Район Советының муниципаль хокукый акты нигезендә бер елга (чираттагы финанс елына) яки өч елга (чираттагы финанс елына һәм план чорына) төзелә һәм раслана.

## 38 статья. Район бюджеты проектын төзү өчен кирәкле белешмәләр

1. Район бюджеты проектын үз вакытында һәм сыйфатлы итеп төзү максатыннан, Район бюджетын төзү өчен җаваплы органнар дәүләт хакимияте органнарыннан, шулай ук Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнарыннан тиешле белешмәләр алырга хокуклы.

2. Район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә юлламасы нигезләмәләренә;

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасына;

бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләренә;

Районның социаль-икътисадый үсеше фаразына;

озак вакытлы чорга бюджет фаразына (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразы үзгәрешләре проекты);

муниципаль программаларга (муниципаль программалар проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).

## 39 статья. Районның социаль-икътисадый үсеше фаразы

1. Районның социаль-икътисади үсеше фаразы чираттагы финанс елына яки чираттагы финанс елына һәм план чорына эшләнә.

2. Районның социаль-икътисади үсеше фаразы Район Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә ел саен эшләнә.

3. Районның социаль-икътисади үсеше фаразы Район Башкарма комитеты тарафыннан Район Советына бюджет проектын кертү турында карар кабул итү белән бер үк вакытта хуплана.

4. Чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) социаль-икътисадиүсеш фаразы план чорының параметрларын төгәлләштерү һәм план чорының икенче елы параметрларын өстәү юлы белән эшләнә.

Социаль-икътисади үсеш фаразына аңлатма язуында фараз параметрларын нигезләү, шул исәптән, фаразланган үзгәрешләрнең сәбәпләрен һәм факторларын күрсәтеп, элек расланган параметрлар белән чагыштыру китерелә.

5. Бюджет проектын төзү яки карау барышында Районның социаль-икътисади үсеш фаразын үзгәртү Район бюджеты проектының төп характеристикаларын үзгәртүгә китерә.

### 40 статья. Бюджет керемнәрен фаразлау

1. Бюджет керемнәре Район Советына Район бюджеты турында карар проекты кертелгән көнгә гамәлдә булган Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары һәм бюджет законнары, шулай ук Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары һәм Район бюджетының салым булмаган керемнәрен билгели торган Район Советының муниципаль хокукый актлары шартларында Районның социаль-икътисади үсеш фаразлары нигезендә фаразлана.

2. Район Советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив-хокукый актларына үзгәрешләр кертүне күздә тота торган, чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) җирле бюджет турында карар проекты Район Советына кертелгән көннән соң кабул ителгән Район бюджетының керемнәре (чыгымнары) үзгәрүгә китерә торган Район Советының норматив хокукый актлары Район Советының әлеге норматив хокукый актларының чираттагы финанс елыннан соң килүче елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча үз көченә керүе турында нигезләмәне үз эченә алырга тиеш.

### 41 статья. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру

1. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру Район Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә торган методика нигезендә һәм тәртиптә башкарыла.

2. Бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру гамәлдәге һәм кабул ителә торган йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләре буенча аерым гамәлгә ашырыла.

3. Бюджет һәм автоном учреждениеләр тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә (эшләр башкаруга) бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) муниципаль йөкләмәне, шулай ук аның хисап финанс елында һәм агымдагы финанс елында үтәлешен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

### 42 статья. Муниципаль программалар

1. Муниципаль программалар Район Башкарма комитеты тарафыннан раслана. Муниципаль программаларны тормышка ашыру сроклары Район Башкарма комитеты тарафыннан ул билгеләгән тәртиптә билгеләнә. Муниципаль программаларны эшләү, әлеге программаларны формалаштыру һәм тормышка ашыру турында карарлар кабул итү тәртибеРайон Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән билгеләнә.

2. Муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләме бюджет чыгымнарының һәр программага туры килә торган максатчан статьясы буенча бюджет турында карар белән Район Башкарма комитетының программаны раслаган муниципаль хокукый акты нигезендә раслана.

Чираттагы финанс елыннан башлап гамәлгә ашыруга тәкъдим ителә торган муниципаль программалар, шулай ук элегрәк расланган муниципаль программаларга үзгәрешләр Район Башкарма комитеты билгеләгән срокларда расланырга тиеш.

Муниципаль программалар бюджет турындагы карар белән аның үз көченә кергән көненнән өч айдан да соңга калмыйча туры китерелергә тиеш.

3. Һәр муниципаль программа буенча ел саен аны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү үткәрелә. Күрсәтелгән бәяләүне үткәрү тәртибе һәм аның критерийлары Район Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

Күрсәтелгән бәяләү нәтиҗәләре буенча Район Башкарма комитеты тарафыннан чираттагы финанс елыннан башлап элек расланган муниципаль программаны туктату яисә үзгәртү, шул исәптән муниципаль программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә бюджет ассигнованиеләре күләмен үзгәртү кирәклеге турында карар кабул ителергә мөмкин.

### 43 статья. Район бюджет проектын төзү тәртибе һәм сроклары

Район бюджеты проектын төзү тәртибе һәм сроклары Район Башкарма комитеты тарафыннан бюджет законнары һәм Район Советының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне үтәп билгеләнә.

## 3 бүлек БЮДЖЕТНЫ КАРАУ ҺӘМ РАСЛАУ

### 44 статья. Район бюджетын карау һәм раслау нигезләре.

1. Бюджет турындагы карарда Район бюджетының төп характеристикалары булырга тиеш, аларга бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты (профицит), шулай ук бюджет законнарында, Район Советының муниципаль хокукый актларында билгеләнгән башка күрсәткечләр (бюджет турындагы карарлардан тыш) керә.

2. Район бюджеты турындагы карар белән түбәндәгеләр раслана:

Район бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеге;

Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге;

чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет чыгымнары классификациясенең чыгымнар төрләренең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары, төркемнәре (төркемнәре һәм төркемнәре) буенча яисә чыгымнар төрләренең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (дәүләт (муниципаль) программалары һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәр (төркемнәр һәм төркемчәләр) буенча һәм (яисә) чыгымнар төрләренең максатчан статьялары (дәүләт (муниципаль)

программалары һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре), төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча, шулай ук Бюджет кодексында, Татарстан Республикасы Законында, Район Советының муниципаль хокукый актында билгеләнгән очракларда бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча да бюджет ассигнованиеләрен бүлү;

чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы;

гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

чираттагы финанс елында һәм план чорында башка бюджетлардан алына һәм Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар күләме;

чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджет расланган очракта план чорының беренче елына шартлы рәвештә раслана торган (расланган) чыгымнарның гомуми күләме бюджет чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 2,5 проценты күләмендә (Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбенә каралган максатчан билгеләнеше булган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча), план чорының икенче елына бюджет чыгымнарының гомуми күләменең кимендә 5 проценты күләмендә (Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджетара трансфертлар исәбенә каралган максатчан билгеләнеше булган бюджет чыгымнарын исәпкә алмыйча);

чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Район бюджеты чыгымнары кытлыгын финанслау чыганаклары;

чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның иң югары чиге һәм (яки) муниципаль тышкы бурычның иң югары чиге, муниципаль гарантияләр буенча бурычның иң югары чиген күрсәтеп;

Район Советының муниципаль хокукый актында билгеләнгән Район бюджетының башка күрсәткечләре.

3. Чираттагы финанс елына һәм план чорына Район бюджеты расланган очракта, расланган Район бюджетның план чоры параметрларын үзгәртү юлы белән һәм аларга Район бюджеты проектының план чорының икенче елы параметрларын өстәү юлы белән раслана.

Район бюджетының план чорының параметрларын үзгәртү Район Советының муниципаль хокукый акты нигезендә башкарыла.

Район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы күрсәткечләрен үзгәртү расланган бюджет ассигнованиеләрен арттыру яисә кыскарту яисә Район бюджетының өстәмә максатчан статьялары һәм (яки) чыгымнар төрләре буенча бюджет ассигнованиеләре чыгымнарын ведомство структурасына кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4. Шартлы рәвештә раслана торган (расланган) чыгымнар дигәндә Район бюджеты чыгымнары классификациясе нигезендә план чорында бүленмәгән бюджет ассигнованиеләре аңлашыла.

5. Район бюджеты турындагы карарда чираттагы финанс елыннан башлап, Район бюджеты турындагы карарда билгеләнгән максатларга, тиешле бюджет ассигнованиеләреннән һәм (яки) Район бюджеты чыгымнарының гомуми күләменнән тыш, кертелергә (бюджетта чагылырга) тәкъдим ителә торган салым булмаган керемнәрнең аерым төрләре (төрчәләре) буенча бюджет керемнәрен куллану каралырга мөмкин.

**45 статья. Район бюджеты проекты белән бер үк вакытта тапшырыла торган документлар һәм материаллар**

1. Бюджет турындагы карар проекты белән бер үк вакытта Район Советына түбәндәгеләр тапшырыла:

бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

агымдагы финанс елының узган чорында Районның социаль-икътисади үсешенең якынча нәтиҗәләре һәм агымдагы финанс елында Районның социаль-икътисади үсешенең көтелгән нәтиҗәләре;

Районның социаль-икътисадый үсеше фаразы;

чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Район берләштерелгән бюджетының төп характеристикалары (бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның, дефицитның (профицитның) гомуми күләме) фаразлары;

Район бюджеты проектына аңлатма язуы;

бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикалар проектлары) һәм исәп-хисаплары;

чираттагы финанс елыннан һәм план чорының һәр елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына муниципаль эчке бурычның иң югары чиге һәм (яки) муниципаль тышкы бурычның иң югары чиге;

агымдагы финанс елына Район бюджетының көтелгән үтәлешен бәяләү;

Район Советы, суд системасы органнары, контроль-хисап палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән, күрсәтелгән бюджет сметаларына карата финанс-бюджет палатасы белән каршылыклар барлыкка килгән очракта тапшырыла торган күрсәтелгән органнарның бюджет сметалары проектлары;

башка документлар һәм материаллар.

2. Муниципаль программалар һәм программага карамаган эшчәнлек юнәлешләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү бюджет турында карар белән расланган очракта, бюджет турындагы карар проектына муниципаль программалар паспортлары тапшырыла.

бюджет турында карар проектында бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү белән кушымта булмаган очракта, бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү белән кушымта бюджет турында карар проектына аңлатма язуына кушымталар составына кертелә.

**46 статья. Район бюджеты турындагы карар проектын Район Советы каравына кертү**

1. Район Башкарма комитеты чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) Район бюджеты турындагы карар проектын Район Советының хокукый актында билгеләнгән срокларда, әмма агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча, Район Советы каравына кертә.

2. Район бюджеты турындагы карар проекты, әлеге Нигезләмә таләпләре нигезендә аңа кушып бирелә торган документлар белән, Район Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе белән, язма һәм электрон формада Район башлыгына озату.......... хаты белән җибәрелә.

3. Район башлыгы бер тәүлек дәвамында, Район бюджеты турындагы карар проектын теркәү өчен, аңа кушып бирелә торган документлар белән Район Советының икътисади сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, алдан карау һәм проект буенча Район Советы аппараты белән берлектә бәяләмә әзерләү өчен җибәрә.

4. Район Советының икътисади сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссиясе бәяләмәсе нигезендә Район башлыгы Район бюджеты турында карар проекты Район Советы тарафыннан карауга кабул ителүе яисә, әгәр тапшырылган документларның һәм материалларның составы әлеге Нигезләмә таләпләренә туры килмәсә, эшләп бетерү өчен кире кайтарылырга тиешлеге турында карар кабул итә.

Район бюджеты турындагы эшләп бетерелгән карар проекты Район Советына бер атна эчендә тәкъдим ителергә тиеш.

## 47 статья. Район Советы тарафыннан Район бюджеты турында карар проектын карау тәртибе

Чираттагы финанс елына бюджет турында карар проекты Район Советына кертелгәннән соң бер тәүлек эчендә, Район Советы рәисе аны экспертиза үткәрү өчен Район контроль-хисап палатасына җибәрә.

Район Контроль-хисап палатасы 1 декабрьгә кадәр ачыкланган очракта әлеге проектның кимчелекләрен күрсәтеп, бюджет турындагы карар проекты турында бәяләмә әзерли.

Район Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе Район Советы депутатлары тарафыннан Район бюджеты турындагы карар проектына төзәтмәләр әзерләгәндә исәпкә алына.

Кертелгән чираттагы финанс елына бюджет турындагы карар проекты Район Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе белән комиссияләргә карауга, шулай ук Район Советы депутатларына җибәрелә.

Район бюджеты турында карар проектын Район Контроль-хисап палатасы бәяләмәсе белән комиссияләргә, шулай ук Район Советы депутатларына җибәрелгәннән соң бер атна эчендә муниципаль берәмлек бюджеты турында карар проектының беренче укылышы үткәрелә.

Беренче укылыш предметы булып муниципаль берәмлек бюджеты турындагы карар проектының төп параметрларын хуплау тора.

Икенче укылышта Район бюджеты турындагы карар проекты тулысынча кабул ителә.

Район бюджеты турындагы карар проекты буенча килешенмәгән сораулар килеп туган очракта, Район Советы рәисе карары белән тигез санда Район Башкарма комитеты һәм Район Советы вәкилләре кергән килештерү комиссиясе төзелергә мөмкин.

Килештерү комиссиясе бәхәсле мәсьәләләрне Район Советы рәисе раслаган регламент нигезендә Район бюджеты турындагы карар проектының беренче һәм икенче укылышлары арасында карый.

Район Советы тарафыннан кабул ителгән чираттагы финанс елына бюджет турындагы карар бер тәүлек эчендә Район Башлыгына кул кую һәм халыкка җиткерү өчен җибәрелә.

## 4 бүлек РАЙОН БЮДЖЕТЫ ҮТӘЛЕШЕ

### 48 статья. Район бюджеты үтәлеше нигезләре

1. Кукмара муниципаль Районы территориясендә Район бюджетының казначылык үтәлеше билгеләнә.

Район бюджетының үтәлешен Район Башкарма комитеты тәэмин итә. Район бюджетының үтәлешен оештыру Район Финанс-бюджет палатасына йөкләнә.

2. Район бюджеты җыелма бюджет язмасы һәм касса планы нигезендә оештырыла.

Район бюджеты касса бердәмлеге һәм чыгымнарның ведомство буйсынуы нигезендә башкарыла.

### 49 статья. Бюджетның җыелма бюджет язмасы

1. Район бюджетын үтәү бюджет язмасы нигезендә башкарыла.

2. Бюджет язмасы бюджет акчаларын бүлүчеләр һәм алучылар буенча баш бүлүче тарафыннан, расланган Район бюджеты нигезендә, Россия Федерациясе бюджетларының квартал саен бүленеп бирелгән чыгымнарының функциональ һәм икътисадый классификацияләре нигезендә төзелә һәм Район бюджеты расланганнан соң 10 көн эчендә Район Финанс-бюджет палатасына тапшырыла.

3. Бюджет акчаларын баш бүлүчеләрнең бюджет язмалары нигезендә Район Финанс-бюджет палатасы, Район бюджеты расланганнан соң 15 көн эчендә, җыелма бюджет язмасын төзи. Җыелма бюджет язмасы Район Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе тарафыннан билгеләнгән тәртиптә раслана һәм Район бюджеты расланганнан соң 17 көннән дә соңга калмыйча бюджетны башкаручы органга җибәрелә. Җыелма бюджет язмасы бер үк вакытта Район Советына һәм Район Контроль-хисап палатасына җибәрелә.

### 50 статья. Керемнәр буенча Район бюджеты үтәлеше

Район бюджетының керемнәр буенча үтәлеше түбәндәгеләрне күздә тота:

- Район бюджетына керемнәрне һәм башка керемнәрне исәпкә алу һәм бүлү буенча операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен, агымдагы финанс елында гамәлдә булган бюджет законнары, бюджет турында карар һәм Татарстан Республикасының башка законнары һәм бюджет законнары нигезләмәләре

нигезендә кабул ителгән муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән нормативлар буенча бүленә торган, Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм башка керемнәрне бүлүдән кергән керемнәрне казначылык счетларыннан Район бюджетының бердәм счетына күчерү;

- артык бүленгән суммаларны күчерү, артык түләнгән яки артык алынган суммаларны, шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган өчен процент суммаларын һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентларны кире кайтару;

- артык түләнгән яки артык алынган суммаларны Россия Федерациясе законнары нигезендә исәпкә алу (зачет);

- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләрне бюджет керемнәре администраторы тарафыннан төгәлләштерү;

Федераль казначылык тарафыннан артык түләнгән яисә артык алынган салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр суммаларын кире кайтару (зачет, төгәлләштерү) өчен кирәкле артык бүленгән суммаларны, акчаларны, шулай ук мондый кире кайтаруны үз вакытында башкармаган өчен процентлар суммаларын һәм артык алынган суммаларга исәпләнгән процентларны, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә, тиешле бюджетларның бердәм счетларыннан керемнәрне исәпкә алу һәм аларны Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында бүлү өчен билгеләнгән Федераль казначылыкның тиешле счетларына күчерү.

## 51 статья. Район бюджетының чыгымнар буенча үтәлеше

1. Район бюджетының чыгымнар буенча үтәлеше Район Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, бюджет законнары таләпләрен үтәп башкарыла.

2. Район бюджетының чыгымнар буенча үтәлеше түбәндәгеләрне күздә тота:

- бюджет һәм акчалата йөкләмәләрне кабул итү һәм исәпкә алу;

- акчалата йөкләмәләрне раслау;

- акчалата йөкләмәләрне түләүне санкцияләү;

- акчалата йөкләмәләрнең үтәлешен раслау.

ПБС агымдагы финанс елында һәм план чорында аңа җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бюджет йөкләмәләрен кабул итә.

ПБС муниципаль контрактлар, физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән башка шартнамәләр төзү юлы белән яисә закон, башка хокукый акт, килешү нигезендә бюджет йөкләмәләрен кабул итә.

3. ПБС казначылык түләүләрен башкару турындагы күрсәтмәләр (алга таба – күрсәтмә) һәм аларны түләүне санкцияләү өчен кирәкле башка документлар нигезендә бюджет акчалары хисабына акча йөкләмәләрен түләү бурычын раслый.

4. Акчалата йөкләмәләрне түләү (гавами норматив йөкләмәләр буенча акчалата йөкләмәләрдән тыш) бюджет акчаларын алучыга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5. Акчалата йөкләмәләрне үтәүне раслау физик һәм юридик затлар, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары файдасына бюджетның бердәм

счетыннан акча күчерүне раслый торган күрсәтмәләр, шулай ук бюджет акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләрен үтәү буенча акчалата булмаган операцияләр уздыруны раслый торган башка документларны тикшерү нигезендә гамәлгә ашырыла.

### 52 статья. Бюджет язмасы

1. ГРБС (РБС) бюджет язмаларын төзү һәм алып бару тәртибе, аларга үзгәрешләр кертүне дә кертеп, Район Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә.

ГРБСның бюджет язмалары җыелма бюджет язмасы белән расланган бюджет ассигнованиеләре һәм Р,айон Финанс-бюджет палатасы тарафыннан расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә төзелә.

РБСның бюджет язмалары бюджет ассигнованиеләре һәм аларга җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары нигезендә төзелә.

2. Бюджет язмасын раслау һәм аңа үзгәрешләр кертү бюджет акчаларын баш бүлүче (бюджет акчаларын бүлүче) (ГРБС (РБС)) тарафыннан башкарыла.

Бюджет йөкләмәләре чыгымнары һәм лимитлары буенча бюджет язмасы күрсәткечләре һәм лимитлары, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 190 һәм 191 статьяларында каралган очраклардан тыш, чираттагы финанс елы башланганчы, ведомство буйсынуындагы бюджет акчаларын бүлүчеләргә һәм (яки) бюджет акчаларын алучыларга җиткерелә.

3. Җыелма бюджет язмасы күрсәткечләре нигезендә ГРБС чыгымнары буенча бюджет язмасы белән расланган күрсәткечләрне җыелма бюджет язмасына тиешле үзгәрешләр кертмичә үзгәртү рөхсәт ителми.

ГРБСның бюджет язмасы күрсәткечләре нигезендә РБС чыгымнары буенча бюджет язмасы белән расланган күрсәткечләрне ГРБСның бюджет язмасына тиешле үзгәрешләр кертмичә үзгәртү рөхсәт ителми.

### 53 статья. Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет үтәлеше

Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча Район бюджеты үтәлеше Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары, администраторлары тарафыннан җыелма бюджет язмасы нигезендә, бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, Район Финанс-бюджет палатасы тарафыннан бюджет законнары нигезләмәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет ассигнованиеләре исәбеннән үтәлергә тиешле акчалата йөкләмәләрне түләүне санкцияләү Район Финанс-бюджет палатасы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

### 54 статья. Район бюджетын үтәгәндә Район бюджеты турындагы карар белән расланганнан тыш фактта алынган керемнәрдән файдалану

Шәһәр бюджетын үтәгәндә Район бюджеты турындагы карар белән расланган керемнәрнең гомуми күләменнән тыш фактта алынган керемнәр, агымдагы финанс елына Район бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертмичә, муниципаль бурыч алуларны алмаштыруга (на замещение), муниципаль бурычларны түләүгә, шулай ук әәлеге Нигезләмәнең 33.2 пунктындагы 33.2 пунктчасында каралган күләмдә бюджет ассигнованиеләре җитмәгән очракта, Районның гавами норматив йөкләмәләрен үтәүгә Район Финанс-бюджет палатасы тарафыннан җибәрелә ала.

Максатчан билгеләнеше булган субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар һәм физик һәм юридик затлардан кире кайтарылмый торган, шул исәптән бюджетка бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә кергән, бюджет үтәлеше вакытында бюджет турындагы карар белән расланган керемнәрдән тыш фактта алынган керемнәр максатчан билгеләнеше булган субсидияләр, субвенцияләр, башка бюджетара трансфертлар бирү максатларына Район бюджеты чыгымнарын арттыруга Чираттагы финанс елына (Чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турында карарга үзгәрешләр кертмичә, җыелма бюджет язмасына үзгәрешләр кертү белән җибәрелә.

## 55 статья. Агымдагы финанс елы тәмамлану

1. Район бюджетын үтәү буенча операцияләр, әлеге Нигезләмәнең 39.2 пунктында күрсәтелгән операцияләрдән тыш, 31 декабрьдә тәмамлана.

Агымдагы финанс елында Район бюджетын үтәү буенча операцияләрне тәмамлау Районның Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

2. Казначылыкның Район бюджетына керемнәрне күчерү буенча операцияләрен төгәлләү, бюджет законнары нигезендә, киләсе финанс елының беренче 5 көнендә башкарыла. Күрсәтелгән операцияләр хисап финанс елы бюджеты үтәлеше турындагы хисаплылыкта (отчетность) чагылдырыла.

3. Бюджет ассигнованиеләре, бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм агымдагы финанс елындагы финанслауның иң чик күләмнәре 31 декабрьдә үз көчен югалта.

Агымдагы финанс елының соңгы эш көнен дә кертеп, казначылык билгеләнгән тәртиптә Район бюджетының бердәм счетында калган акчалар чикләрендә түләү өчен санкцияләнгән Бюджет йөкләмәләрен түләргә тиеш.

4. Район бюджетының бердәм счетында булмаган бюджет акчаларының бюджет акчаларын алучылар тарафыннан кулланылмаган калдыклары агымдагы финанс елының соңгы ике эш көненнән дә соңга калмыйча Район бюджетының бердәм счетына бюджет акчаларын алучылар тарафыннан күчерелергә тиеш.

5. Агымдагы финанс елында кулланылмаган, максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертлар алар бирелгән бюджет кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Бюджет акчаларының баш администраторының субсидияләр рәвешендә алынган бюджетара трансфертлар һәм максатчан билгеләнештәге бүтән бюджетара трансфертлар формасында алынган, агымдагы финанс елында

файдаланылмаган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турында карары нигезендә күрсәтелгән бюджетара трансфертларның калдыкларыннан артмаган күләмдә акчалар чираттагы финанс елында алар элек бирелгән бюджет кеременә, күрсәтелгән бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган бюджет чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен кире кайтарылырга мөмкин.

Максатчан билгеләнештәге субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгы тиешле бюджет керменә күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Район Финанс-бюджет палатасы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә, алар бирелгән бюджет керменә алынырга тиеш.

Районның Финанс-бюджет палатасы агымдагы финанс елы тәмамланганда бюджет акчаларын алучыларны чираттагы финанс елының гыйнвар аенда Россия Федерациясендә эшләми торган бәйрәм көннәрендә аларның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле акчалар белән тәэмин итү тәртибен билгели.

## 5 бүлек БЮДЖЕТ ХИСАБЫН ТӨЗҮ, ТЫШКЫ ТИКШЕРҮ, КАРАУ ҺӘМ РАСЛАУ НИГЕЗЛӘРЕ

......................

### 56 статья. Бюджетны исәпкә алу һәм хисап нигезләре

1. Бюджет исәбенең һәм бюджет хисабының бердәм методологиясе Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан бюджет законнары нигезләмәләре нигезендә билгеләнә.

2. Бюджет исәбе Районның финанс һәм финанс булмаган активларының һәм йөкләмәләренең торышы, шулай ук әлеге активларны һәм йөкләмәләрне үзгәртә торган операцияләр турында акчалата чагылыштагы мәгълүматны җыю, теркәү һәм гомумиләштерүнең тәртипкә салынган системасыннан гыйбарәт.

Бюджет исәбе Россия Федерациясенең бюджет классификациясен үз эченә алган счетлар планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Бюджет хисабы үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) Район бюджеты үтәлеше турында хисап;

2) Район бюджеты үтәлеше балансы;

3) эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләре турында хисап;

4) акча хәрәкәте турында хисап;

5) аңлатма язуы.

4. Бюджет үтәлеше турындагы хисапта Россия Федерациясе бюджет классификациясе нигезендә керемнәр, чыгымнар һәм Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча бюджет үтәлеше турындагы белешмәләрне үз эченә ала.

Район бюджетының үтәлеше балансы Районның финанс һәм финанс булмаган активлары, хисап чорының беренче һәм соңгы көненә бюджет исәбе счетлары планы буенча йөкләмәләр турында мәгълүматларны үз эченә ала.

Эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләре турында хисабы хисап чорында эшчәнлекнең финанс нәтиҗәләре турында мәгълүматны үз эченә ала һәм идарә секторы операцияләрен классификацияләү кодлары буенча төзелә.

Акчалар хәрәкәте турындагы хисап дәүләт идарәсе секторы операцияләрен классификацияләү кодлары буенча бюджетлар счетлары буенча операцияләрне чагылдыра.

Аңлатма язмасында Район бюджеты үтәлеше һәм бюджет хисабының анализы, шулай ук хисап финанс елында муниципаль йөкләмәнең үтәлеше һәм (яки) ГРБС (РБС, ПБС) тарафыннан бюджет ассигнованиеләрен куллануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр тупланган.

## 57 статья. Бюджет хисабын төзү

ГРБС Район бюджеты керемнәренең баш администраторы, Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы (алга таба – бюджет акчаларының Баш администраторлары) бюджет акчаларын бүлүчеләр (бюджет акчаларын алучылар), бюджет керемнәре администраторлары, бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары администраторлары тарафыннан аларга бирелгән бюджет хисабы нигезендә җыелма бюджет хисабын төзиләр һәм аны Район Финанс-бюджет палатасына тапшыралар.

2. Районның бюджет хисабы бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының җыелма бюджет хисабы нигезендә Район Финанс-бюджет палатасы тарафыннан төзелә.

3. Районның бюджет хисабы еллык була. Район бюджеты үтәлеше турында хисап квартал саен була.

4. Районның бюджет хисабы Район Финанс-бюджет палатасы тарафыннан Район Башкарма комитетына тапшырыла.

5. Агымдагы финанс елының беренче кварталында, ярты еллыгында һәм тугыз аенда Район бюджеты үтәлеше турындагы хисап Район Башкарма комитеты тарафыннан раслана һәм, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына хисап тапшыру срогы тәмамланганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча, Район Советына һәм Район Контроль-хисап палатасына җибәрелә.

Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап Район Советы карары белән расланырга тиеш.

## 58 статья. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү

1. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисап, Район Советында аны караганчы, бюджет средстволары баш администраторының бюджет хисабын тышкы тикшерүне һәм Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләүне үз эченә ала торган тышкы тикшерү узарга тиеш.

2. Район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапны тышкы тикшерү, бюджет законнары таләпләрен үтәп һәм федераль законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, Район Советының муниципаль хокукый актында билгеләнгән тәртиптә Район Контроль-хисап палатасы тарафыннан башкарыла.

3. Район Башкарма комитеты, агымдагы елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча, аңа бәяләмә әзерләү өчен, Район бюджеты үтәлеше турында хисап бирә. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисапка бәяләмә әзерләү бер айдан да артмаган срокта башкарыла.

4. Район Контроль-хисап палатасы бюджет акчаларының баш администраторларының еллык бюджет хисабының тышкы тикшерү мәгълүматлары нигезендә Район бюджеты үтәлеше турындагы хисапка бәяләмә әзерли.

5. Район бюджеты үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә Район Контроль-хисап палатасы тарафыннан Район Советына, бер үк вакытта Район Башкарма комитетына да җибәреп тапшырыла.

**59 статья. Район бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тәкъдим итү, карау һәм раслау**

1. Узган финанс елында Район бюджеты үтәлеше турындагы хисап район Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан, агымдагы елның беренче маеннан да соңга калмыйча, Район Советы карары проекты рәвешендә Район Советына тапшырыла.

Район бюджеты үтәлеше турындагы хисап структурасы буенча Район Советының хисап елына, шул исәптән кушымталарны да кертеп, Район бюджеты турындагы карарына туры килергә тиеш.

Узган финанс елында Район бюджеты үтәлеше турындагы хисап белән бер үк вакытта Район Советына түбәндәгеләр җибәрелә:

Район бюджеты үтәлеше турында карар проекты;

узган финанс елына Районның социаль-икътисади үсеш нәтиҗәләре турында хисап;

Район бюджеты үтәлеше турында аңлатма язуы;

,Район Башкарма комитеты җитәкчесенең резерв фонды үтәлеше турында хисабы;

Район бюджетыннан бюджет кредитлары бирү һәм бирелгән кредитларны түләү турында хисап;

барлык гарантия алучылар буенча Районның бирелгән муниципаль гарантияләре турында хисап;

муниципаль милектәге Район милкен файдалану турында хисап;

муниципаль унитар предприятиеләрнең, Районның автоном учреждениеләренең табышлылыгын һәм зыянлылыгын анализлауны кертеп, икътисадның муниципаль секторын үстерү планын үтәү турында хисап.

2. Район бюджеты үтәлеше турындагы хисап өч көн эчендә Район башлыгы тарафыннан Район Советының барлык комиссияләренә җибәрелә.

3. Район Советы утырышында Район Башкарма комитеты җитәкчесенең, яисә аның ризалыгы буенча Районның Финанс-бюджет палатасы җитәкчесенең Район бюджеты үтәлеше турындагы доклады тыңлана.

Район бюджеты үтәлеше турындагы хисап буенча фикер алышу һәм карау нәтиҗәләре буенча Район Советы түбәндәге карарларның берсен чыгара:

- Район Советы тарафыннан Район бюджеты үтәлеше турындагы хисапны раслау һәм тиешле карар кабул итү турында;

- әгәр аны үтәгәндә Россия Федерациясе Бюджет кодексы бозылуга юл куелса, Район бюджеты үтәлеше турындагы хисапны кире кагу турында.

Район Советы тарафыннан Район бюджеты үтәлеше турындагы карарны кире кагу очрагында, ул мәгълүматларны дөрес булмаган яки тулы булмаган чагылдыру фактларын бетерү һәм бер айдан да артмаган срокта кабат тапшыру өчен кире кайтарыла.

### 60 статья. Район бюджеты үтәлеше турында карар

Район бюджеты үтәлеше турындагы карар белән хисап финанс елы өчен Район бюджеты үтәлеше турында Район бюджеты керемнәренең, чыгымнарының һәм дефицитының (профицит) гомуми күләме күрсәтелгән хисап раслана.

Хисап финанс елында Район бюджеты үтәлеше турындагы карарга аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

- бюджет керемнәрен классификацияләү кодлары буенча Район бюджеты керемнәре күрсәткечләре;

- Район бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча Район бюджеты чыгымнары күрсәткечләре;

бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча Район бюджеты чыгымнары күрсәткечләре;

- бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча Район бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары күрсәткечләре;

Район бюджеты үтәлеше турындагы карар белән, Район бюджеты үтәлеше турында карар кабул итү өчен, бюджет законнарында һәм Район Советының муниципаль хокукый актларында билгеләнгән башка күрсәткечләр раслана.

## 6 бүлек МУНИЦИПАЛЬ ФИНАНС КОНТРОЛЕ

### 61 статья. Муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыручы органнар

1. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә тышкы муниципаль финанс контроле Район Контроль-хисап палатасының контроль эшчәнлеге булып тора.

2. Бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә эчке муниципаль финанс контроле Район Финанс-бюджет палатасының контроль эшчәнлеге булып тора.

3. Муниципаль финанс тикшерүе органнарының бюджет вәкаләтләре Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә билгеләнә.